**Казан шәһәре Мәскәү районы**
**«Г.Ибраһимов исемендәге**
**17 нче татар гимназиясе»**
**гомуми муниципаль бюджет учреждениесе**



# *Галимҗан Ибраһимов исемендәге XII республика фәнни-гамәли конференция: укытучыларның тезислары*

**Казан**
**2023 нче ел, 25 нче март**

# Тезисы педагогической секции

*Составитель: Агзамова Д.Р.*

*Секционный сбор данных: Галиева А.Р.*

Секция «Педагогика и музейное дело»………………………………………………………3-79 с.

Тезисы педагогов (отправленные в указанный срок и оформленные по правилам) **не рецензируются, не редактируются, публикуются с сохранением авторской орфографии** на официальном сайте гимназии портала «Электронное образования РТ» МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова» Московского района города Казани.

## Секция «Педагогика и музейное дело»

### Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү алымнары

**Романова Галина Николай кызы**

*Зәй муниципаль районының «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

"Нәрсәгә өйрәтергә һәм ничек өйрәтергә?"-бу мәсьәлә нәкъ менә безнең заманда актуаль булып тора, чөнки мәгариф системасында бик күп үзгәрешләр бар. Бүгенге көндә укучылар төрле кирәкле белем күнекмәләргә ия булырга тиеш. Бу максатка ирешү өчен без балаларда функциональ грамоталылык формалаштырырга тиеш. Функциональ грамоталылык – кешенең әйләнә-тирә мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, гомердәвамында алынган белемнәрен куллана белү сәләте. Функциональ грамоталы шәхес яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхес булып үсәргә тиеш.

Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше. Ул –укучыда текстларны аңлау, куллану, бәяләү, алар турында уйлану сәләте үстерә.

Бу максатны үз эченә алган инновацион технологияләрнең берсе – тәнкыйди фикерләү технологиясе. Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе үз позициясеңне яклый һәм җиткерә алу, әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, аргументларга нигезләнеп, логик фикер йөртә белү сәләте.

Тәнкыйди фикерләү технологиясендә <u>укытучы</u>

1.Укучының эшчәнлегенә юнәлеш бирә;

2.Мөстәкыйль фикер йөртергә этәргеч ясаучы шартлар булдыра;

3.Төрле фикерләрне каршы куя;

4.Нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

<u>Укучы</u>

1.Куелган проблеманы чишә;

2.Дәлилләр эзли;

4.Башкаларның фикерен тыңлый;

5.Бәхәсләшә;

6.Бәя бирә.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора:

Өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту→төшенү(аңлау)→рефлексия.

Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема буенча укучының белемнәрен актуальләштерү һәм уку эшчәнлегенә кызыксыну уяту өчен кирәк.

Төшенү (аңлау) этабында укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, алган белемнәрен яңалары белән бәйли.

Рефлексия этабында укучы өйрәнгәннәрне бербөтен итеп күзаллый, аңлап гомумиләштерә, яңамәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясе ысуллары:

Алымнарның берничәсенә тукталып китәсем килә.

“Чуалган логик чылбыр”алымы.

Дәреснең рефлексия өлешендә укылган текстның ачкыч сүзләре чуалтып бирелә. Укучылар шуны тәртипкә салалар, дөреслиләр.

Яисә аерым битләргә текстта сурәтләнгән 5-6 вакыйга языла. Укучылар шуны хронологик яки сәбәп –эзләнү тәртибендә эзлекле чылбыр итеп урнаштырырга тиеш. Фикерләр тыңланып беткәч, карар кабул ителгәннән соң, укытучы чыганак текстны укый, укучылар чагыштыра. Буалым укучыларның игътибарын һәм логик фикерләвен үстерә.

Якташыбыз Мөдәррис Әгъләмовның шигыреннән берничә юл бирелә, “Чуалган логик чылбыр” ысулын кулланып, сүзләрне шигырь юлларына куярга кирәк.

Җирем-________, илем-________,
______________йөрергә мөмкин,
Имичә башны________________...
Чөнки,___________булсамда,
____________минем белән!

Файдалану өчен сүзләр: матурлык, иркен, горур, түбән, киң, кайда.

Инсерт ысулы.

Бу ысулны икенче төрле “текстны тамгалау” дип атыйлар. Укучыларны тамга кую билгеләре белән таныштырып чыгарга кирәк, чөнки текстның кырыена тамгалар куеп барырга туры киләчәк.

∨*(галочка)* тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

+*(плюс)* тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

–*(минус)* тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

**?***(сорау)* тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

Бу ысулны куллануның уңышлы ягы шунда, укучы текстны пассив укымый, ә белергә, аңларга теләп, игътибар белән кат-кат укый.

Рефлексияэтабындатаблицагатеркәлгәнбарлыкэшанализлана,фикералышына.

Зәебезгә370елтулды,шушыуңайданЗәйтарихытурындатекстбирелә.

Текстны игътибар белән укыгыз, һәм инсерт ысулын кулланып, текстның кырыена, поляга тамгалар куеп барыгыз.

Зәй исеме тарихта XIV гасырдан билгеле.

Таҗетдин Ялчыгол язуынча да, бүгенге кайбер галимнәрнең фикеренчә дә, Кол Гали безнең якташыбы булып чыга.

Зәй шәһәренә нигез салыну вакытын бүгенгечә хисапласак, 2022–918=1104 килеп чыга.

Димәк, Зәй каласына кимендә 1104 яшь!

Мең еллар элек Зәй елгасы буенда фин-угор кабиләләре яшәгән.

VI-VII гасырларда алар Урта Азиядән килгән төркетләргә буйсынганнар.

VII гасыр башында Бөек Венгрия дәүләте барлыкка килә.

Беркадәр вакыттан соң аларны болгар кабиләләре кысрыклап чыгара һәм Бөек Болгар дәүләтен төзиләр.

Зәй елгасының түбән өлешендә табылган кабер ташлары болгар кабиләләренә карый.

Крепость ДалаЗәе елгасының биек уң ярында 1652 елның язында салына башлый.

Зәй якларына Е.Пугачев үзенең гаскәре белән 1773 нче елның 24 декабрендә килеп җитә.

А.С.Пушкин үзенең“ Пугачев тарихы” нда яза: “ЕкатеринаII, Зәй крепостенең сугышсыз бирелүенә ачуы килеп, үзенең указы белән шәһәр статусын бетерә һәм халыкның күп өлешен тирә-як авылларга тарата”.

Нәтиҗә.

Әлеге без карап, эшләп киткән алымнар уку грамоталылыгын үстерү өчен бик отышлы дип саныйм. Алар уйланырга мәҗбүр итә, эзлеклелекне булдырырга, вакыйгаларны тәртип белән урнаштырырга өйрәтә. Сүз байлыгын арттыра, сүзләрне урынлы кулланырга этәрә. Текстны уку барышында вакыйгаларны күз алдына китерергә ярдәм итә. Укучылар текстны аңлыйлар, уку материалын җиңел үзләштерәләр.

**Укучыларны татар теленә өйрәтүдә цифрлы технологияләр - Онлайн-курслар куллану**

**Смирнова Гөлнара Рәшәт кызы**

*Советлар Союзы Герое М.С.Фомин исемендәге 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге укытучы мөгаллим һәм шәхес буларак нинди сыйфатларга, күнекмәләргә ия булырга тиеш? Яңа гасыр укытучысы уку-укыту процессында нәтиҗәлелеккә ни рәвешле ирешә ала – болар барсы да бүгенге көннең иң актуаль яңгырашлы проблемаларның берсе. Мәсьәләне чишүдә алга китеш сизелә, уңышка китерә торган юл-сукмакларның берсен цифрлы технологияләр белән эшләү тәшкил итә. Мин бу технологияләргә мөрәҗәгать итүне түбәндәге аспектларда карарга тәкъдим итәм:

цифрлы технологияләр ярдәмендә белем бирү процессында нинди уңай нәтиҗәләргә ирешергә була?

татар теле һәм әдәбияты укытучысы мондый технологияләр белән эшләгәндә, нинди авырлыклар белән очраша?

авырлыкларны җиңү юлындагы табышлар.

Соңгы берничә елдагы эш тәҗрибәмә таянып әйтә алам, рус балаларын татар теленә өйрәтүдә цифрлы технологияәр, бигрәк тә Онлайн-курслар төзү һәм тәкъдим итү мөмкинлеге алгарышлы укытуда уңай нәтиҗәләргә китерә. Алгарышлы укыту тәгълиматлары С.Н. Лысенкова тарафыннан узган гасыр урталарында ук тәкъдим ителә, әмма бүгенге көндә аларны тормышка ашыруның яңа юллары, алымнары, инструментлары пәйда булды. Шундыйлардан цифрлы технология биргән мөмкинлекләр турында аерым сөйләр идем. А.Шляйхер “Образование мирового уровня. Как выстроить школьную систему XXIвека” дигән хезмәтендә хәзерге вакытта цифрлы технологияләрне куллана алмаучылар җәмгыятьнең тулы канлы әгъзалары, икътисади һәм мәдәни тормышның актив катнашучылары була алмый” дип яза [Шляйхер, 2018: 282]. 2019 һәм аннан соңгы елларда, бөтен дөнья пандемия йогынтысын тойган вакытта уку-укыту системасы үзен саклап кына түгел, онлайн-укыту ярдәмендә яңа баскычка күтәрелә алды. Дөрес, без, татар теле укытучылары билгеле бер авырлыклар белән дә очраштык. Укучылар цифрлы технологияләр кулланып эшләнгән эш төрләреннән дәрестә уңышлы һәм теләп куллансалар да, үзләре татар телле Интернет-секторын белем алу максатларында нәтиҗәле куллана алмауларын күрсәттеләр, мондый секторга битараф булу, аны куллануга мотивациянең көчсезлеге эшебездә беркадәр таркаулыкка китерде. Шуны җиңү максаты белән, мин татар теленнән онлайн-курслар тәкъдим иттем. Шуларны куллану буенча кайбер эш алымнарым белән уртаклашыр идем.

Мондый эш төре укучыларны татар телле Интернет-секторы белән эшләргә этәрә, ярыш моментлары цифрлы технологияләр биргән мөмкинлекләрне тулы файдаланырга мотивация тудыра, төркемнәрдә төрле темалар өстендә (елгалар, кошлар, файдалы казылмалар һ.б.) эшләгән укучыларның бергә җыелуы дәресләр циклы дәвамында алар арасында уңай хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнашуга китерә.

**Роль школьного музея в патриотическом воспитании школьников**

***Хайруллина Гульсина Рашидовна***

*МБОУ «Школа 99», учитель истории и обществознания высшей квалификационной категории, руководитель школьного музея*

Важнейшим инструментом духовно-нравственного становления личности, источником формирования лучших человеческих качеств является гражданско-патриотическое воспитание школьников.

В настоящее непростое время нашему государству жизненно необходимо воспитывать патриотов, способных вывести страну из экономического, политического, нравственного кризисов, защитить Россию от любого нашествия извне и любых проявлений терроризма.

Одним из надежных способов воспитания патриотизма, гражданственности у учащихся является музейная деятельность по вовлечению учащихся во внеурочную работу.

Главные воспитательные задачи, которые я ставлю во внеурочной деятельности и на уроках истории и татарского языка, это

- воспитание творческого и ответственного отношения к труду на благо других людей, своей малой родины;
- формирование культуры межнационального общения, толерантности;
- формирование правовой и нравственной культуры гражданина;

Главное при выборе подходов к воспитанию личности, я считаю создание условий для самореализации в пространстве своей школы, класса, района, города и равное партнерское сотрудничество: ученик и учитель, который дает возможность достойно учиться и развиваться.

Важную роль гражданско-патриотического воспитания является школьный музей, который призван способствовать формированию патриотических качеств, расширению кругозора и воспитанию познавательных интересов и способностей, овладеванию учащимися навыками поисковой, исследовательской деятельности урочной и внеурочной деятельности.

Именно школьный музей в неформальной обстановке развивает у ребят творческую активность, коллективизм, сплоченность и авторитет.

В 2001 году в школе № 92 (ныне №99) Московского района был открыт музей «Боевой и Трудовой Славы школы и жителей микрорайона Левченко».

Главной целью работы музея является гражданское и патриотическое воспитание у учащихся через исследовательскую и творческую деятельность, через кружок «Юный краевед», где я являюсь руководителем.

По своему профилю наш музей связан с историей возникновения, строительства и развития поселка и завода «Полимерфото», в своих экспозициях отражает героический подвиг наших земляков и работников завода и тыла.

Девиз музея - "Никто не забыт, ничто не забыто". Работа музея строится на принципах толерантности, историзма, сотрудничества, ответственного отношения к делу. Хочется отметить, жизнедеятельность нашего музея зависит от слаженной работы учительского коллектива и обучающихся, где каждый чувствует себя комфортно.

В этом году была проделана огромная работа по восстановлению документов, плана и программы развития музея. Получили Российское признание Свидетельство №18004, как краеведческий школьный музей «История поселка имени Левченко и завода «Полимерфото» от 29.11.2015 года.

Программа развития музея предусматривает мероприятия по фальсификации истории Отечества. На базе музея проводятся уроки по истории России и истории Татарстана, в 8-9ом классе по темам «Быт и обычаи», «Татария в годы войны и послевоенное время», «Советский тыл», «Великая Отечественная война», на примерах конкретных героев, личностей и воочию с источниками музея закрепляется историческая закономерность, подлинность и память. Успешно применяются приемы умственных действий: рассказ, описание, сравнение, анализ, характеристика. Урок становится ярким и интересным элементами: чтение фронтовых писем, цитат, просмотр фрагментов фильмов, стихами,

прослушивание музыкальных произведений, которые пробуждают любовь и уважение к своей Родине, своим корням (на уроках приемы: оживи картину, логическая цепочка, ключевые термины, ромашка вопросов от простого к сложному).

В экспозиции школьного музея имеются подлинные материалы, письма, документы, фотоальбомы, которые раскрывают важнейшие этапы Великой Отечественной войны, героические подвиги ветеранов войны и тыла, жителей поселка Левченко.

Функции музея: сбор материалов, хранение письменных, вещественных, исторических источников, сохранение и поддержание экспозиций в надлежащем порядке. Музей состоит из 10 экспозиций, подаренных картин Ю.Ананьева и фотоальбомов завода «Полимерфото».

В школьном музее традиционно работает кружок «Юный краевед». Есть и Актив музея, которые курируют и организуют мероприятия, встречи и круглые столы, проводят заседания. Основные направления работы кружка – подготовка и проведение тематических, интерактивных экскурсий, оформление наглядно-практического материала для подготовки экскурсоводов.

В кружке учащиеся работают с литературой, справочниками, документами, знакомятся с архивными музейными материалами, обращаются за помощью в сборе материалов к родственникам, ветеранам войны и тыла, учатся наблюдать, анализировать, обмениваются опытом, передают свои знания другим, приобретают навыки исследовательской деятельности, защищают свои проекты в рамках предметных недель. В рамках патриотического месячника в феврале каждый класс выпускает газеты, Боевые листки, проводятся смотры строя песни.

В этом учебном году в рамках благотворительности кружок «Юный краевед» старшая группа провела обзорные экскурсии коррекционному детскому саду №149, для детей с девиантным поведением РСОШ№1 под названием «Известные и неизвестные земляки», «Подвиг воина и творца». Наш экскурсионный проект «Мужество, скромность и талант» в сотрудничестве с Национальным музеем получила признание и печаталась в журнале «Казан».

Самыми яркими можно назвать встречи с афганцами «Афганистан в душе моей», с Советом ветеранов поселка Левченко, с волонтерами общественных организаций. Такие встречи, круглые столы на базе нашей школы давно не было. Они были так важны, наши дети получили эмоциональный заряд и живой жизненный урок истории, появился интерес к армейской службе.

Многолетний опыт показывает целесообразность проведения музейных уроков, интегрированных уроков в самом музее (ОРКСЭ и окруж. мир, история и литература, ИЗО) или использования отдельных экспозиций в различных классах. Краеведческие материалы оказывают помощь учителю в изучении татарского языка, культуры и обычаи разных народов, национальные кастюмы и быта, история нашего края разных в веках. На уроках татарского языка и литературы ученики выполняют интересные задания по составлению генеалогического древа (Шәҗәрә - означает дерево), ведь каждому важно знать родословную своих предков, у татар заведено знать до седьмого колена со стороны отца и матери. Здесь подключаются родители и родственники, им самим интересна история своего рода и семьи. Историческое прошлое и возрождение традиций обладают мощным воспитательным потенциалом, основанным на близких ребенку понятиях: любовь к родителям, родным местам, родному укладу жизни.

В школе учатся и общаются дети разных национальностей и конфессий, никогда между ними не возникали конфликты. Толерантность проявляется в проведении различных праздников «Масленица», «Науруз», «Сабантуй», «Курбан байрам» «День Святого Валентина». В поселке есть мечеть «Сулейман», и храм «Всецарица», посещение которого оставляет восторг и удивление наших детей. Наш видеоролик мечеть «Сулейман» был показан в конкурсе школьных музеев, за что получили грамоту в номинации. Как видите, это заслуга, огромный труд учителей не одного месяца. Ребята в общении, во взаимодействии быстро учатся понимать и принимать другой язык.

Для повышения эффективности урока, его воспитательного значения классным руководителям предлагается предусматривать работу учащихся в музее и использовать музейные материалы в соответствии с учебной и воспитательной программой (использовать материалы на славных страницах советской авиации, о жизни и творчестве Ананьева, и мастер золотых рук Хайдара Искандерова, о героях земляках локальных воин).

Собранный краеведческий материал дает возможность участвовать в научно-практических конференциях, в конкурсах экскурсионных проектов. Уже в начальных классах дети знакомятся с понятием проект и с помощью учителя составляют предметные мини-проекты.

Краеведческое направление реализуется через проектно-исследовательские работы в деятельности кружка «Юный краевед». Дети готовят экскурсии, исследовательские работы на актуальные темы, а моя роль в этом: направлять, контролировать, корректировать и помогать в оформлении работы.

Экскурсоводом-исследователем может быть каждый школьник, кто любит музей и галереи, умеет интересно рассказывать, и желает их передать другим. Подготовка и проведение экскурсий — дело не простое, требует кропотливого труда, усидчивости и времени, специальных знаний и навыков. Работа по выявлению юных экскурсоводов начинаю с 5 класса. На уроках истории в 5-6 классах дети получают домашние задания в форме заочного путешествия по темам «Древняя Греция», «Древний Египет», «Владимиро-Суздальское княжество», «Золотая Орда». А в кружке с октября, 3месяца идет обучение и подготовка юных талантливых экскурсоводов, которые будут представлять нашу школу в различных конкурсах-конференциях, из всех способных выбираю «самых лучших». Именно «лучшие» приносят успех и победу.

Для начальных классов проводим «День музея в начальной школе», викторины, экскурсии с презентацией «Что такое музей?» «Какие музеи бывают», в среднем звене тематические экскурсии «Голоса родного края», «Их именами названы улицы», «Чьим именем назван наш поселок», в старшем звене литературно-исторические «История завода «Полимерфото», «Серебряный век Казани», «Шишкинские места Казани» и др. Юные экскурсоводы в ходе подготовки и проведения мероприятий развивают творческую самостоятельность, речевую культуру, приобретают навыки и опыт. Актив музея проводит конкурсы творческих работ: «История моей семьи в истории страны», «Родом из семьи», «Их именами названы наши улицы…», «Загляните в семейный альбом» и т.д. В музее представлен самодельный стенд «Бессмертный полк» с фотографиями прадедов.

Мои ученики ежегодно участвуют в традиционных городских конкурсах «Казань – город сердце моего», «Казань - сегодня, завтра», «Юные экскурсоводы», «Ожерелье Татарстана», «Путешествие к истокам», получая много грамот и дипломов. Я всегда говорю, если есть звезды, их можно зажечь и в маленькой школе, было бы только желание и терпение. Материалы музея под названием «Чьим именем назван наш поселок Левченко», «Подвиг воина и творца» являются визитной карточкой нашего музея, которая бесспорно, в настоящее время является стимулом и мотивацией развития коммуникативных умений учащихся.

Двери музея всегда открыты для родителей учащихся и гостей школы на общешкольных собраниях, для желающих была проведена обзорная экскурсия, пришедшие охотно смотрели альбомы, фотографии, нашли себя в этих фотографиях, ведь многие из них работники завода «Полимерфото». История завода, о его банкротстве написано в известной книге Л.Н. Столпнера «Казанский завод Полимерфото».

Таким образом**,** школьный музей обладает практически неограниченным потенциалом воспитательного воздействия на умы и души детей и подростков. Он даёт возможность детям попробовать свои силы в разных видах научной, технической и общественной деятельности. Участвуя в сборе экспонатов для музея, в экскурсиях школьники получают нравственную закалку, учатся жить, осознавая свою причастность к судьбе Отечества, его прошлому, настоящему, будущему, проявляют активную жизненную позицию.

Итак, на фоне роста подростковых асоциальных действий и пагубных пристрастий опыт показывает, что предлагаемые формы и приемы воспитания, музейной работы эффективны и жизнеспособны, их дальнейшее совершенствование будет способствовать воспитанию нравственно достойных граждан России.

**Башлангыч сыйныфларда туган телне өйрәтүдә мәгълүмати технологияләр куллану**

**Әминова Рима Сөнгатул кызы**
**Рәхимова Ризәлә Камил кызы**

*Кукмара муниципаль районының «Р.И.Зарипов исемендәге Байлангар урта мәктәбе»нең башлангыч сыйныф укытучылары*

Заманча мәгариф системасы укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштыруда укытучыларны инновацион технологияләр куллануга этәрә. Соңгы елларда мәгариф өлкәсе шактый зур үзгәрешләр кичерде. Уку-укыту системасына электрон технологияләр ныклап үтеп керде. Белемле, көндәшлеккә сәләтле , тормышта үз юлын табарга әзерлекле, тиешле карарлар кабул итә торган шәхес тәрбияләү өчен, искечә эш итү генә җитәрлек түгел бүген.

Башлангыч сыйныфта укытуның федераль дәүләт стандартлары да бездән укучыларны белем нигезләренә дифференциаль өйрәтүне таләп итә. Шунлыктан, кече яшьтәге мәктәп укучыларына белем бирүдә яңа мәгълүмати технологияләр куллану зарур.

Нәрсә соң ул инновацион технологияләр һәм аның үзенчәлеге нидә? Без аны яңалык дип кабул итәбез. Латин теленнән ул, "яңалыкка омтылу" дип тәрҗемә ителә. Узган гасырда Джордж Боткин бу алымның укучы мөстәкыйль чишелеш эзләвен, килеп туган хәлдән чыгу юлларын табуы дип аңлаткан.

Без, башлангыч сыйныф укытучылары, укыту технологиясен тормышка ашырганда, аны педагогик эшчәнлекнең конкрет шартларына туры китереп кулланабыз. Укыту-тәрбия сыйфатын күтәрү, укучыларның осталыгын үстерү максатыннан яна белем чыганакларын табу – безнең төп бурычыбыз. Чөнки интернетта һәр кулланучыга үзенең материалларын, эшкәртмәләрен куярга мөмкинлек бар. Интернет челтәре ресурсларын куллану белем алучыга кирәкле информацияне таба белергә, анализларга, системага салырга ярдәм итә.

Сберкласс, Учи.ру, Белем.ру, Еду татар.ру белем бирү платформаларында шактый бай материал тупланган: спектакльләр, кинофильмнар , олимпиада эшләре, интерактив уеннар. Алар аралашу компетенциясен беренче планга куялар, укучыларны күбрәк сөйләштерүгә корылган. Җаваплар бирү рәвешендә укучыларны әңгәмәгә тартабыз.

Әзер электрон продуктлар, аудио-язмалар, мультимедиалы презентацияләр, кыска роликлар дәресләрне җанландырып җибәрү өчен менә дигән материал.

Педагогларның хезмәте балаларның тәрбияле булуында, белемендә, төрле дәрәҗәдә узган олимпиада һәм бәйгеләрдә ирешкән уңышларында чагылыш таба. Укучыларыбызның елда фәнни-гамәли конференцияләрдә, иҗади бәйгеләрдә, олимпиадаларда ирешкән уңышлары зур.

Сыйныфтан тыш чаралар, фәнни эзләнү эшләре буенча презентацияләр төзибез. "Әлифба" бәйрәме," Беренче хәреф көне" кебек бәйрәмнәрне интеллектуаль уеннар, тренинглар кулланып оештырабыз.

Татар теленә өйрәтүдә инновацион технологияләр арасыннан проектлар методын куллану аерым урын алып тора. Бу метод белән эшләгәндә, укучыларның уйлау-фикерләү эшчәнлеге активлаша. Без, федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп татар теле һәм уку дәресләрендә мини-проектлар методын кулланабыз . Мәсәлән, Гарәфи Хәсәновның " Табигать җырчысы" әсәрен өйрәнгәндә укучылар, кошлар һәм җәнлекләр дөньясының байлыгын күрсәттеләр, Кызыл китапка кертелгән үсемлекләрне, хайваннарны аерып алып, проект төзеп якладылар.

Проект эшчәнлеген оештыру тел өйрәнүгә, сәнгатьле сөйләмгә кызыксыну уята. Чөнки мини-проект яклаганда сәләте төрле булган укучылар да үз фикерләрен җиткерә, уртак нәтиҗәгә киләләр.

Туган тел ул - халыкның көзгесе. Татар әдәби теленә кызыксыну уяту өчен без еш кына буктрейлер (китапнамә) һәм плейкаст кебек интернет челтәренең яңа эш төрләренә мөрәҗәгать итәбез. Белгәнегезчә, күләме буенча зур булмаган бу видеороликлар китаплар укуга, тел өйрәнүгә этәргеч бирә, мавыктыргыч формада таныш булмаган яңа китаплар эчтәлеге белән кызыксындыра. 4 нче сыйныфта Разил Вәлиев иҗатын өйрәнгәндә шагыйрьнең "Кайтаваз кайда яши?", Фәнис Яруллинның "Биюче бака" китапларына ясаган китапнамәләрне сыйныфтан тыш уку дәресләрендә кулландык. Аны әзерләгәндә үзебезгә укучыларда яңа китаплар укуга мотивация уяту максаты куйдык. Нәтиҗәдә,

башлангыч сыйныф укучылары үзләренең яшь үзенчәлекләре буенча, укыган әсәрләр вакыйгаларына, геройларына плакат формасында постерлар ясадылар.

3 нче сыйныфта татар теленнән сүз төркемнәрен өйрәнәбез. Кабатлау дәресендә төркемнәрдә һәр сүз төркеменә кластер төзү бурычы куелды. Кластер дәрес материалын график калыпка салуны күздә тота. Төп мәгънәне белдергән сүз уртага языла, аңардан төрле якка киткән уклар бу сүзне ачыклаучы башка сүз, сүзтезмәләр белән бәйли. Шулай итеп, бер сүзне, төшенчәне ачыклаучы бик күп мәгълүмат җыела. Укучыларның үзара ярдәмләшүен акивлаштыруга юнәлтегән эш формасы буларак, эшчәнлекне төркемнәрдә оештыру кластер төзүдә уңай нәтиҗәләр бирде. Бер-берсенең фикерен тыңлап, стандарт булмаган карарлар кабул иттеләр, мәгълүмат ташкынында иркен аралашырга өйрәнделәр. Әлеге ысул теманы өйрәнүне тәмамлаганнан соң, материалны үзләштерү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен уңайлы.

Без үз белемебезне үстерү белән бергә эш тәҗрибәсен хезмәттәшләребез белән дә уртаклашабыз. Мәгълүмати технологияләрне өйрәнү кысаларында эш тәҗрибәсен төрле мәйданнарда яктыртабыз: Бөтенроссия “ФГОС класс” конкурсында –диплом, төбәкара “Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел” иҗади конференциядә- грамота, Республика фәнни-практик “Һөнәргә беренче адымнар” конференциясендә- дипломнарга лаек булдык. Республика ” Ел укытучы” конкурсы лауреатына ия булуыбыз да эш нәтиҗәбезнең күрсәткече булып тора.

Тәҗрибә уртаклашу укытучыларның методик берләшмә утырышларында, семинарларда дәвам итә. Иновацион технология буенча ясаган чыгышларыбызны ”Башлангыч сыйныфларда яңа технологияләр куллану”, “Түгәрәкләрне оештыру тәҗрибәсеннән”, “Дәрестән тыш эшчәнлек” дигән буклетларда урнаштырдык.

Безнеңчә, дәресләрне эшлекле атмосферада үткәрүдә, укучыларны фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә җәлеп итүдә, аларның шәхси сыйфатларын, әхлакый кыйммәтләрен, иҗади активлыгын формалаштыруда укытуның инновацион методлары зур әһәмияткә ия.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар телен һәм әдәбиятын укытуда нинди генә алдынгы технологияләргә нигезләнсәк тә – укучыларны аңлы һәм планлы рәвештә үз өсләрендә эшләргә өйрәтү, теләп укуны тәэмин итү, үз чиратында бу эш белән оста итеп идарә итү мөһим, ә төп таләп бер - нәтиҗәгә ирешү.

**Әдәбият дәресләрендә уку грамоталылыгы формалаштыру**

**Шаева Венера Мнахир кызы**

*Мөслим муниципаль районының «Тат. Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Хәерле көн, хезмәттәшләрем. Бүген без мастер класста барыбызны да борчыган берничә сорауга бергәләп җавап эзләрбез. Кулланган алымнарны байлык итеп үз букчагызга туплап барыгыз. Башладык.

Пышылдап, сер итеп әйтелә: Монда күргән, сөйләгәннәрне беркемгә дә әйтә күрмәгез, алайса мине эштән ку-а-чак-лаааар((((

Нәтиҗә: Әһә, тып-тын калдыгыз, чыш-пыш килеп алдыгызмы? Бу - дәрес башлаганда кулланырга мөмкин булган беренче алым – "ИНТРИГА"

Нәтиҗә: Әйе, мин дә ышанмыйм. Икенче алым ничек атала?

"Ә СЕЗ МОҢА ЫШАНАСЫЗМЫ?" Әлеге алымны дәрес башында кирәкле төшенчәләрне, мәгълүматны аера белү, мотивация өчен кулланырга мөмкин.

Теманы чыгарту: Сүзләр болытына карагыз. Бүген сөйләшәчәк теманы, максатларны билгелик.

"Сүзләр болыты" ясау өчен интернетта шушы сүзне язып эзләү җитә. Бу – тагын бер алым.

2 өлеш. Ачкыч-төшенчәләр белән эш.

ФГОС таләбе буенча, функциональное чтение һәм читательская грамотность дигән ике төшенчә билгеле. Слайдка карагыз.

Функциональ грамоталылык әдәбият дәресендә <u>тулысынча</u> формалаштырыла торган күнекмә түгел, чөнки әдәбият образлар, сәнгатьлелек чаралары, эмоциональ өлкә белән бәйле.

3 өлеш: Гамәли биремнәр. 3 төркемгә 3 төрле текст тәкъдим ителә. Диагональ буенча укыйбыз. Төп сүзне билгелибез. (кушымтада)

Текстларны нинди уртак идея берләштерә? Глоссарий ярдәмендә билгеләгез.

Без нинди алым кулландык?

Анализ ясаганнан соң, игенче хезмәтенә багышланган җырлар тыңларга, табышмаклар әйтергә, сынамышлар табарга була. Болар – текст белән эш төрләре. Аннары Лотфулла Фаттаховның "Игеннәр өлгерде" картинасы буенча сочинение язу бер дә авырлык тудырмас иде.

2 рәсем тәкъдим итү: кырмыска оясы һәм үзеннән зуррак йөк тартып баручы кырмыска.

Бирем. Ике рәсемне берләштереп, башыгызга килгән бик "акыллы" бер фикерне әйтегез. (фикерләрне тыңлау)

Ә хәзер

<u>"РЕСТАВРАТОР" КҮНЕГҮЕ </u>тәкъдим итәм. "Сүзләр болыты"нда бирелгән сүзләрдән җөмлә әйтегез

Равил Фәйзуллин аны болайрак әйткән:

Шигырьгә нинди исем куяр идегез? (җаваплар тыңлана)

Ә Р.Фәйзуллин бу дүртьюллыкны Үҗәтлек дип атаган.

А) Мондый күренешне күзәткәнегез бардыр. Кырмыска турында нинди характеристика биреп була? Тырыш, үҗәт, максатчан, кайгыртучан... Җир йөзендәге барлык җан иясе дә кояшка тартыла. Шул исәптән, кеше дә.

Өч кенә тезмәле шигырь <u>аллегорик образлылык</u> ярдәмендә өч мөстәкыйль фикерне калкытып куя.

<u>Беренчедән,</u> ул һәркемнең үз максатына ирешү юлы барлыкны ассызыклый.

<u>Икенчедән,</u> кешенең зур омтылышлар (кояшка якынаю!) белән тормышка аяк басуын искәртә.

<u>Өченчедән,</u> шәхеснең һәр җиңүне кояшка якынаю буларак карауча көчле рухына бәя бирә.

Б) фикерләрегезне модель, кластер, схема рәвешендә күрсәтегез.

В)Табышмак язып карыйк. Рефлексия.

## Татар теле дәресләрендә электрон сүзлекләрне куллану

**Госманова С.М., Алиева Ф.Н.**

*Казан шәһәре Мәскәү районының 94 нче гимназиясенең укытучылары*
*Шәрәфетдинова Л.М. Казан шәһәре Идел буе районының*
*139 нчы гимназия-Мәгариф үзәгенең укытучысы*

Эшенең төп максаты – электрон сүзлекләрнең төрләре, татар һәм рус мәктәпләрендә уку эшчәнлегендә электрон сүзлекләрне кулгануның әһәмиятен күрсәтү.

Бурычлар:

- электрон сүзлекләр ярдәмендә теоретик һәм практик белемнәр бирү;
-электрон сүзлекләр ярдәмендә укучыларның язма һәм телдән сөйләм күнекмәләрен үстерү;
- электрон сүзлекләр булган сайтлар белән танышу, эшләргә өйрәнү;
- электрон сүзлекләрне дәрестә куллану дәрәҗәсен үстерү.

Әлеге эштә электрон сүзлекләрнең әһәмияте, алар белән мәктәптә укучыларның эшчәнлеген оештыру турында теоретик мәгълүмат тупланган, мисаллар китерелгән. Хезмәттә тупланган материалларны мәктәп укытучыларына укучыларның эшчәнлеген оештыру буенча методик ярдәмлек буларак тәкъдим итеп була.

Сүзлекләрдән эзлекле рәвештә файдаланганда гына тиешле нәтиҗәләргә ирешеп була, укучыларның сүзлек запасын арта, сөйләмендәге ялгышлары төзәтелә, укучыларның танып белү эшчәнлекләре, мөстәкыйльлекләре үсә. Мисал өчен, 8 нче сыйныфның Луиза Батыр-Болгарый биографиясенә багышланган текста “зәвык” сүзе кулланылган. Бу сүзне аңлар өчен иң беренче чиратта китаптагы сүзлекне карыйлар, анда “вкус” дип тәрҗемә ителгән. Укучылар аны тәм төю белән кабул итәләр. Бу очракта әлеге күзаллау туры килми һәм электрон сүзлекләрдән икенче мәгънәне эзлиләр.

Киләсе эш төре, ул – крассвордлар. Алар махсус сүзлекләр белән эшләсеннәр өчен эшләнелгән, чөнки анда синонимнар, антонимнар, омонимнарны табарга кирәк. Мондый эшләр өйгә бирелә, билгеле өйдә кәгазь сүзлекләр юк. Менә шул вакыт безгә электрон сүзлекләр ярдәмгә килә.

Шулай ук кәгазь һәм электрон сүзлекләрнең уңай һәм тискәре яклары каралды. Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була, кәгазь сүзлекләр тулырак, әмма күләмле һәм эш тизлиге түбән, ә электрон сүзлекләр белән эш заманча, тиз ләкин күзләр сәламәтлегенә заралы һәм тулы түгел.

Биредә үзебез еш куллана торган интернет ресурсларны күрсәтеп киттек (татзет тупланмасы, мобиль кушымталар, гугол һәм яндекс тәрҗемәчеләр, азатлык әлбәттә, сайты).

Сүзлекләр белән җентекләп планлаштырылган һәм яхшы оештырылган эш - укучыларның сүзлек запасын баета, орфографик грамоталылыкны үстерә, укучыларның сөйләмен үстерергә ярдәм итә, ә гомумән, тел культурасын үстерергә, балада игътибар, туган телгә карата хөрмәт һәм мәхәббәт формалаштырырга ярдәм итә. Һәр эшнең уңай ягы булган кебек тискәре яклары да очрый. Электрон сүзлекләр белән эш барышында укучылар белән шуңа игътибар иттек, сүзлекләрнең кирәк дәрәҗәдә тулы булмавына, бер сүз өчен берничә сүзлек ачарга туры килә. Бу исә үз чиратында балаларда тискәре караш тудыра. Укытучыларның тырышып аларны бу эшкә этәргән көчләре юкка чыга. Киләчәктә электорн сүзлекләр тулыландырылыр дип ышанып калабыз. Әмма В.А. Сухомлинскийның әйткән сүзләрен искә төшерсәк: «Дәрес — укытучының гомуми һәм педагогик культурасының көзгесе, аның интеллектуаль байлыгы, аның күзаллаулары һәм эрудициясе күрсәткече ул». Әлбәттә, укытучылар да, укучылар да замана таләпләреннән читләшмиләр, яңа технологияләрне, шул исәптән электрон сүзлекләрне үз эшчәнлекләрендә һәрдаим кулланалар.

## Әдәби музей эшчәнлеге аша укучыларда әхлакый кыйммәтләр тәрбияләү

**Касыймова Зөһрә Габбас кызы**

*Арча муниципаль районының«Утар-Аты төп гомуми белем мәктәбе»*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге заманда мәктәп укучыларына бик күпне белергә, һәр яңа мәгълүматны үзләштереп барырга туры килә. Чөнки көндәлек тормышыбыз, яшәү – көнкүрешебез белемле булуны таләп итә. Алган белемне мәктәп бусагасын атлап чыккач та куллана алырга, аптырап, югалып калмаска кирәк. Безне әйләндереп алган мохиттә укучы кайсы ягы белән булса да үзенчәлекле, ягъни көндәшлеккә сәләтле дә булырга тиеш. Менә шушы шартларда патриотик, эстетик, мәдәни культура ничектер артка таба, икенчел планга күчә кебек. Ләкин шәхес тау кадәр белемле булып та, тәрбияле булмаса, бу белемне эшкә җигә алыр идеме икән? Ныклы белем мөһимрәкме, әллә соң яхшы тәрбияме?

Һичшиксез, гыйлемлелек һәм әдәплелек укучыда бер-берсен тулыландырып торучы ике канат ул.

Мәктәбебез педагоглары менә шушы ике критерийны күздә тотып эш итә. Без балаларны заман таләп иткәнчә, ягъни көндәшлеккә сәләтле, милли рухта, тәрбияле итеп яшәргә әзерләргә тиешбез. Ләкин шушы биеклеккә ничек ирешергә, бүгенге күптөрле мәгълүмат чорында, ялгышмыйча ничек үз сукмагынны сайлап алырга? Укучыларда мөстәкыйль булу, камил булырга омтылу, үз-үзеңне раслый алу сәләтләрен ничек үстерергә?

Әлеге максатларга ирешү, укучыларны үз сәләтләрен сынап карау өчен нигез булдыру ниятеннән, 2005 нче елдан бирле, мәктәбебездә язучы, фронтовик-шагыйрь Әхмәт Исхак музее эшләп килә.

Музей эшчәнлеге аша бик куп күренекле шәхесләр белән аралашырга, укучыларыбыз белән очрашу кичәләре уздырырга мөмкинлек туды.Танылган тарихчы, язучы, Ә. Исхак белән якыннан аралашкан М. Хәбибуллин, язучы-эзтабар Шаһинур Мостафин, Гөлсем ханым Исхакова, Яңа гасыр телеканалыннан үзенең төшерү группасы белән Гөлнара Зиннәтуллина, шагыйрьнең улы Илдар Әхмәтович-ул Себердә таможня начальнигы булып эшли, оныгы Олег Ильдарович, килене Надежда Степановна, Резеда Вәлиева, Роза Туфитулова, Татарстан Дәүләт Милли архивыннан Наилә Йосыповаларны күрүгә ирештек. Күренекле шәхесләребез музейда зур эшләр башкарылганына, Әхмәт Исхак иҗаты онытылмаганына рәхмәт хисләрен җиткерделәр.

Син җиңелдең , диңгез,
Чын дуслыкның,
Киң колачлы көче алдында,
дип яза Ә. Исхак “Син җиңелдең, диңгез!” шигырендә.

Ә бу шигырьнең язылу тарихы бик үзенчәлекле. Диңгез буенда ял иткәндә Ә. Исхак һәм Муса Җәлил бергә туры киләләр. Эчкә йөзеп кергән яшь Җәлил диңгез дулкыннарына каршы тора алмыйча, бата башлый. Әхмәт ага аны коткарып кала. Шушы вакыйгага карата оештырылган кичәне без “Син җиңелдең, диңгез” дип атадык. Бу кичәдә әдәби тәнкыйтьче «Мәдәни җомга» газетасының баш редакторы, шагыйрь Зиннур Мансуров һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары, шагыйрь Факил Сафин , Ш.Абдюшев - «Мәдәни җомга» газетасының фотокорреспонденты катнашты.

Алар үзләренең мәкаләләре, шигырьләре, Әхмәт ага турында истәлекләре белән таныштырдылар, музейга, мәктәпкә бүләкләр тапшырдылар. Ә иң зур бүләк – күренекле рәссам Эрот Зарипов иҗат иткән портрет! Музей ачылып, 2 ел узгач, Ә. Исхак портретына ия булуга ирештек.

Әхмәт ага Исхак Габдулла Тукай иҗаты белән кызыксына. Бик күп шигырьләре Г. Тукай иҗатын өйрәнүен, олылавын күрсәтеп тора. Зиннур Мансуровның Габдулла Тукайга багышлап, “Ике яклап янган шәм” дигән мәкаләсе буенча конференция укучыларыбызда кызыксыну уятты. Автор бу кичәдә үзе дә катнашты. Шушы ук елда мәктәбебездә шагыйрә Җәмилә Әхтәмова белән очрашу булып узды.

Язучылар белән аралашу традициясен дәвам итеп, Әхмәт Исхакның хатыны Гөлсем ханым, шагыйрь Рашат Низами, Шәриф Камал музее хезмәткәре Равилә апа бездә кунакта булдылар. Алар

укучылар көче белән әзерләнеп, Ә. Исхакка багышланган “Сүнмиләр, яктылык сибәләр, көрәштә кабынган язмышлар” , дип исемләнгән кичәне карадылар, музейда булдылар, укучылар белән сөйләштеләр.

Казанда Ш. Камал музеенда Ә. Исхакны искә алу кичәсе уздыруда катнаштык. Бер төркем язучылар белән очрашуга безнең мәктәп укучылары да чакырулы иде. Без бу чакыруны бик теләп кабул иттек һәм укучыларыбыз Казанда чыгыш ясап, телевидениегә интервьюлар бирделәр.

Кремльдәге Сәнгать музеенда бер төркем укучылар белән Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар каршында Ә. Исхак шигырьләре белән чыгыш ясап кайттык. Бу чыгышыбыз өчен музей җитәкчелеге укчыларыбызга музейның һәр бүлегендә бушлай экскурсия уздырдылар.

Музейның фондын һәрвакыт тулыландырып киләбез. Музей оештыруның төп максаты итеп, класс җитәкчеләренә, фән укытучыларына дәресләр, тәрбия сәгатьләрендә ярдәм итүне алдык. Конкрет педагогик ситуацияләрдә укучыларда мөстәкыйль булу, камил булырга омтылу, үз-үзеңне раслый алу сәләтләрен үстерүдә музей танып-белү, эстетик, культура-агарту, ял вакытын оештыруда ярдәмче булырга тиеш.

Музей берничә бүлектән тора: “Әти-әнием-ике канатым”, “Хыялларга бай яшьлек”, “ Бергә үтелгән юллар”, “Очрашу- үзе бер гомер”, “Сугышта узган юллар”. Һәр бүлеккә экскурсовод билгеләнгән. Экспозиция материаллары даими тулыландырылып тора. Музейда инвентарь китабы тутырыла. Музей программасының максат һәм бурычлары, бу программаның үтәлеше, шартлары, этапларга бүленеш эзлекле алып барыла.

Узган уку елында 8 нче класс укучылары виртуаль музей эшләп мәктәп сайтына урнаштырдылар. Арча мәгариф идарәсе сайты аша кереп тә музей һәм аның эшчәнлеге белән танышып була.

Олуг әдибебез Гомәр Бәширов бер язмасында: “Мин ышанам: халыкны халык иткән изге гадәтләрне, кимү юлына баскан асыл сыйфатларны, онытыла язган затлы һөнәрләрне яңадан аякка бастыру халкыбызның данын, күршеләре белән дус яшәүче киң күңелле халык дигән яхшы исемен тагын да югарырак баскычка күтәрер!”- дип язган. Әйе, бәһасез рухи байлыгыбыз җәүһәрләре кешелеклелек, миһербанлылык, шәфкатьлелек, әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүдә ышанычлы җирлек булып тора, әби-бабаларыбыз һөнәрләренә карата мәхәббәт тәрбияли. Ә яңа информацион чаралар аша халкыбызның бөек улларын-кызларын дөньяга таныту-безнең бурычыбыз.

**Уку грамоталылыгын формалаштыруда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясен куллану**

**Гарифуллина Дилбәр Рафак кызы,**
**Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы**

*Мөслим муниципаль районының “Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү - мәгариф системасында бүген актуаль проблема. Безнең төп бурыч – укучылар яңа белем – күнекмәләргә ия булсын һәм көндәлек тормышта алган белемнәрдән, эффектив технологияләрдән нәтиҗәле файдалана алсын өчен, барлык мөмкинлекләр һәм шартлар тудыру.

Уку грамоталылыгы - функциональ грамоталылыкның төп компоненты. Уку грамоталылыгын формалаштыру өчен, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә нәрсәгә басым ясап эшләргә соң? Моңа кадәр яшәп килгән гадәти дәресләр белән генә чикләнеп калмыйча, яңача эш итүне таләп итә ул.

Безнең алда нәкъ менә уку грамоталылыгын формалаштыруда иң нәтиҗәле технологияләрне сайлап алып, аны үзләштерү зарурлыгы туды. Укытучыдан бүген иҗадилык, креативлык сорала. Чөнки заманча фикерләүгә омтылган укытучы гына укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп тәрбияли ала.

“Кешегә балык бир, ул бер көн тук була, син аны балык тотарга өйрәт- ул көн дә тук була”, дигән мәкаль бар. Без сезгә үз дәресләребездә кулланылучы тәнкыйди фикерләү технологиясен – укучыларны уйланырга өйрәтүдәкулыбыздагы беренче коралны бирәбез. Функциональ грамоталы шәхес үстерү, ягъни белем, күнекмә, осталык ярдәмендә төрле тормыш мәсьәләләрен чишүгә сәләтле һәм зур шәхес тәрбияләүдә әдәбият фәне мөмкинлекләрен куллану укытучының зыялылыгына, актив тормыш позициясенә гомуми компетентлылыгына бәйле булу бәхәссез.

Укучыга нәтиҗәле белем алу өчен нәтиҗәле алымнар кулланып, уңай шартлар булдыру – укытучының бурычы һәм шул ук вакытта һөнәри осталыгын күрсәтү мөмкинлеген бирүче чара.

Тәнкыйди фикерләү технологиясе элементларын куллану укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның өстенлекле бер алымы булып тора. Эшебездә без “Ике яклы көндәлек”, “Өч яклы көндәлек”, “Борт журналы”, “Инсерт”, “Фишбоун” (балык скелеты), “Фикерләр кәрзине” (Идеяләр кәрзине), “Интеллект карта” (Прием “Mind Map”), “Кластер”, “Алты эшләпә”, “Блум ромашкасы”, “Аңлатмалы (комментарий биреп) уку” һәм башка алымнарны күрсәттек.

Баланың фәнне кызыксынып өйрәнүе укытучы шәхесенә бәйле. Укытучы үз фәнен никадәр яратса, белсә, ул аны укучыларына тапшыру юлларын эзли һәм нәтиҗәле юллар, алымнар таба. Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгак итеп, шуны әйтәсе килә: мөстәкыйль фикер йөртергә, коллективта үз фикерен әйтә белгән бала беркайда да югалып калмый. Укучылар эшчәнлеген оештырганда, без дә һәр дәрестә тәнкыйди фикерләү технологиясен куллану аша функциональ грамоталылыкны үстерүгә зур игътибар бирергә омтылабыз.

Гомумән алганда, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатында кулланыла торган алымнар бихисап. Текст яки мәгълүмат белән эшләү уку процессы структурасында мөһим урын алып тора. Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да текст белән эшләүнең мөмкинлекләре күп. Алардан уңышлы файдалану гына кирәк! Чөнки “алдымызда торган бөек үзгәрешләрдә мәктәпнең, тәгълим-тәрбиянең бик зур роль уйнаячагы, мәктәп нинди генә нигезгә төзелсә дә, анда тел-әдәбият дәресләренең беренче урынны тотарга тиешлеге үзеннән-үзе билгеле бер мәсьәләдер”...

**Музей дәресләре**

**Сафина Гөлүсә Солтан кызы**

*Балтач муниципаль районының «Салавыч күппрофильле лицее»ның башлангыч сыйныфлар укытучысы*

Соңгы елларда милләтебезнең үткәне, тарихы белән кызыксыну артты. Халкыбызның рухи мирасын барлау, торгызу, динебезгә хөрмәт уяту юнәлешендә яхшы гамәлләр башкарыла. Кешелек өчен хас булган намуслылык, гаделлек, шәфкатьлелек, олыларны хөрмәт итү кебек асыл сыйфатлар онытыла төшеп, матди байлыкка күбрәк омтылу көчәйгән заманда, мондый эшләр бик тә кирәк. Шуңа күрә яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә алдыбызга яңа бурычлар килеп баса. Шундый бурычларның берсе – яшь буында милли үзаң үстерү, ягъни үз халкының тарихын белүче һәм аны хөрмәт итүче, үз милләте белән горурланучы шәхес тәрбияләү. Нәкъ менә шушы бурычларны хәл итүдә лицеебызда оештырылган «Туган якны өйрәнү музее» безгә ярдәмгә килә.

Музейдаүткәрелгәнчараларыарасындахәзергевакыттаиң популяр музей дәресләре. Музей дәресегадидәресләрдәнһәмэкскурсияләрдәнтамырданаерылып тора, ул «төсле» тарихивакыйгаларгабик бай.

Мондый дәресләрдә балаларга күңелсез түгел.Укучылар парта артында утырмыйлар, ә музейдагы предметларны өйрәнәләр, бер-берсе белән зирәклек һәм тапкырлыкта ярышалар: табышмаклар, ребуслар чишәләр, музей хезмәткәрләре һәм педагог белән сәяхәткә вакытында шул чорга сәяхәт итәләр, шул вакытның геройлары итеп үзләрен хис итәләр.

Музей экспонатлары бер үк вакытта баладан интеллектуаль, көчле ихтыярлы һәм эмоциональ шәхес ясау өчен уникаль мөмкинлеккә ия.

Музейдагы дәрес укучыларга билгеле бер укыту программасы буенча белемнәр алу, дәрестә алган белемнәрне ныгыту һәм тирәнәйтү максатыннан оештырыла.

Музейда дәресне уздыруның нәтиҗәлелеге укучыларда яңа төшенчәләр формалаштыруга, шулай ук элек алган белемнәрне системалаштыруга һәм киңәйтүгә ярдәм итә. Кагыйдә буларак, элек үткән материалны ныгыту буенча музей дәресләре нәтиҗәле уза.

Уку процессының үзенчәлекле булуы (музей мохите) укучыларның танып белү мәнфәгатьләрен генә түгел, ә аларны һәрьяклап үстерүгә дә этәрә. Танып белү феномены зур әһәмияткә ия – предметлар турында булган белемнәрне төп нөсхәләрнен үзләре тикшерү, абстракт белемнәрне конкрет белемнәргә әйләндерә.

Музейдагы дәрес көчле һәм фәннәрне авыр үзләштерүче укучыларны да бертигез дәрәҗәдә активлаштыра, чөнки музей мәгълүматларын кабул итүнең төрле дәрәҗәсенә индивидуаль якын килергә мөмкин.

Укытучы җитәкчелегендә музей дәресләре, дәресләр циклын эзлекле үткәрү укучыларда музей культурасын тәрбияли.

Музейда үткәрелгән дәресләр, практика күрсәткәнчә, гадәти сыйныфта үткәрелгәннәргә караганда күбрәк эффект бирә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: телебезне, милләтебезне саклап калуда, туган җиребезгә һәм хакыбызның үткәненә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү дә лицейның «Туган якны өйрәнү музее»нда үткәрелгән дәресләр зур роль уйный. Чөнки милли традицияләргә нигезләнгәндә генә лицей үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын тулысынча үти ала.

**Башлангыч сыйныф дәресләрендә заманча технологияләр куллану**

**Хәйруллина Нурия Васил кызы**

*Казан шәһәре Мәскәү районы*
*Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы*

Хәзерге заман мәктәбенең иң зур бурычы – бүгенге җәмгыяткә киләчәктә дә Туган ил язмышы өчен җаваплы, халыкара мөнәсәбәтләр корырга әзер, мобиль, хезмәттәшлеккә сәләтле, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итә белүче, әхлаклы һәм белемле шәхес тәрбияләү. Заманында **Г.Ибраһимов “Күп белүгә караганда да, азбелдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр,”** - дип язып калдырган. Әдип, өйрәтү дигәндә, баланы тормышка әзерләүне дә күздә тоткан. Мин дә шушы принциптан чыгып эш итәм, даими рәвештә эзләнәм, яңалыкка омтылып, укучыларның сәләтенә һәм мөмкинлекләренә туры килә торган кызыклы, иҗади биремнәр эзлим, укучыларның фәнгә карата кызыксыну уятуга, иҗади фикерләүсәләтләрен үстерүгә юнәлдерелгән методик алымнар, заманча технологияләр кулланырга тырышам.

Заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

-укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;

-укучының танып белү активлыгын арттыру;

- укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, инициативасын тагын да үстерү .

Әдәби уку дәресләрендә **продкутив уку**технологиясен куллану укучыларны аңлап укырга, кирәкле информацияне табарга өйрәтә. Түбәндәге биремнәрне кулланып була:

- **“Разведчиклар “** уены.Яңа әсәр белән танышу этабында текстны укыр алдыннан сорау бирелә. Тексттан бу сорауга тиз генә җавап табып укырга кирәк була.
- **Геройны җанландыр.**Үзеңне әдәби персонаж урынына куеп, маҗараларың, кичерешләрең, хисләрең турында сөйлә. Башка укучылар геройга әсәрнең эчтәлеге буенча сораулар да бирәләр
- **Тере картина** — әдәби әсәрдәге моментны төрле реквизитлар, персонажларның киемнәре, кыяфәт һәм торышлары ярдәмендә күрсәтү
- **Тавтограммалар:**бер үк хәрефтән башланган сүзләрдән генә торган хикәя төзү

**Тәнкыйди фикерләүне үстерү** технологиясе дә отышлы дип саныйм. Бу технологиянең “Ыргытылган таш”, “Фаразлар агачы“, “Идеялар кәрҗине”, “Беләм, белергә телим, белдем”, “Логик чылбыр”, “Үзара сорау биреш”, “Дөрес, дөрес түгел”, “Кластер”, “Синквейн” алымнарыукучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерә, фантазияләрен баета, предметлар, вакыйгалар арасындагы логик бәйләнешне табарга, объектив фикер йөртергә өйрәтә. Бу алымнарны математика, туган тел, рус теле һәм әйләнә – тирә дөнья фәннәрендә дә кулланып була. Шулай ук бу алымнар аша укучыларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә, сүзлек запасы арта. Мондый иҗади эшләрне башкару укучылар өчен җиңел, күңелле һәм файдалы да.

**Уен технологиясен** куллану да да уңай нәтиҗә бирә. “Кар йомарламы”, “Мин кем яки нәрсә?”, “Баскыч”, “Ватык телефон” уеннары да укучыларга бик ошый. Татар теле дәресләрендә “Артык сүзне тап”, “Охшаш һәм аермалы яклар” (белем, дәрес, акбур, җөмлә - барлык сүзләр дә биш хәрефтән, ике иҗектән тора, нәрсә? соравына җавап бирәләр, исем булалар, тартык авазга тәмамланалар; аермалы яклары: акбур сүзе калын әйтелә, кушма сүз, сузык аваздан башлана) “Качкан сүзне тап”, “Нәрсә үзгәрде?” “Мин нинди сүз уйладым?” («әйе» яки «юк» дип җавап бирерлек сораулар бирү ярдәмендә), “Аңлатып кара” **(Ниндидер предметка яки күренешкә билгеләмә бирү),** “Эзлеклелекне дәвам ит” (Мәсәлән Д, С, Ч, П,...- башта закончалыкны белергә кирәк; бу мисалда атна көннәренең беренче хәрефләре алынган), “Булмастыр” (фантастик хикәя төзү) кебек уеннар, анаграммалар, ребуслар чишү еш кулланыла. “Укытучы хатасы” дигән алым укучыларны активлаштыра, уйларга мәҗбүр итә.

Укытуны камилләштерүнең чиге юк, бары эзләнергә, яңалыкка омтылырга, куелган максатка кыю барырга кирәк. Заманча технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып, аларны үзләштереп, дөрес файдалана белү уңышка ирешергә ярдәм итә дип уйлыйм.

**Формы работы с разными видами информации при обучении английскому языку как основа развития читательской грамотности школьников**

**Хайбуллина Гузял Назыровна**

*учитель английского языка*
*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова» г.Казани*

Результаты проведенного международного тестирования для 15-летних школьников ***PISA***, которая оценивает функциональную грамотность учащихся и умения применять знания на практике показали, что у обучающихся существуют проблемы в формировании грамотности чтения. Поэтому обновлённый документ ФГОС говорит о необходимость формирования функциональной грамотности школьников.

Функциональная грамотность - это способность использовать все постоянно приобретаемые в жизни знания, умения и навыки для решения максимально широкого диапазона жизненных задач в различных сферах человеческой деятельности, общения и социальных отношений.

Одним из направлений функциональной грамотности является ч**итательская грамотность.**Какое бы задание не получил учащийся, нужно сначала это задание **прочитать** и понять.Развитие читательской грамотности - это направление очень актуальное и самое востребованное. В этом направлении работают все школы страны, подготавливая учащихся к ВПР, а выпускников к ГИА.Читательская грамотность - способность понимать и использовать тексты, размышлять о них, читать, чтобы достигать своих целей, расширять знания и возможности, участвовать в жизни общества.

Чтение является важным компонентом урока английского является, который предполагает самостоятельную работу ученика как с текстовым материалом, так и другими источниками информации (таблицы, графики, рисунки и тп). И это должно быть не просто чтение и перевод, а выполнение заданий на формирование навыков функционального чтения. Функциональное чтение - это чтение с целью поиска информации для решения конкретной задачи или выполнения определенного задания.Формирование читательской грамотности на уроках иностранного языка предполагает работу над развитием следующих **компетенций** у учащихся:

- Умение находить и извлекать необходимую информацию из текста т.е. ориентация в содержании текста (умение определять главную тему, общую цель или назначение текста; выбирать из текста или придумать заголовок; формулировать тезис, выражающий общий смысл текста; объяснять порядок частей, содержащихся в тексте; находить в тексте требуемую информацию и т.п.).
- Умение интегрировать и интерпретировать информацию, т.е. умение преобразовывать текст, используя новые формы представления информации: формулы, графики, диаграммы, таблицы; сравнивать и противопоставлять заключённую в тексте информацию разного характера; обнаруживать в тексте доводы в подтверждение выдвинутых тезисов и т.п.
- Умение, направленное на осмысление и оценку прочитанного в тексте, т.е. откликаться на содержание текста; оценивать утверждения, сделанные в тексте, исходя из своих представлений о мире; находить доводы в защиту своей точки зрения и т.п.
- Умение использовать информацию из текста (для решения практических задач)

Эти умения согласно PISA считаются высшим уровнем развития читательской грамотности.

**Реконструкция стендов Литературного музея Г.Ибрагимова (системный подход)**

**Агзамова Динара Рустэмовна**

*педагог дополнительного образования высшей категории,*
*руководитель Литературного музея Галимзяна Ибрагимова*
*МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», г.Казань*

Литературный музей Галимзяна Ибрагимова был открыт в Казани в 1962 году на базе 89 школы. Фонды музея перешли в МБОУ «Татарская гимназия №17 имени Г.Ибрагимова», которая была открыта на месте 89 школы в 1991 году.

В 2012 году Литературный музей Г.Ибрагимова был совсем другим. Когда я стала его руководителем, первым делом решила изменить контент фотографий, который не соответствовал стандарту музейной экспозиции из-за внешних повреждений (выцветание, обрыв контура, ошибки в надписях и т.п.). Была проведена работа по обновлению и замене фотографий. Оригинальные фото переместились в альбом писателя, на стендах появились аккуратные копии.

Сами стенды носили разрозненный формат. Не было единого ансамбля. У противоположных стен находилось от пяти до шести стендов. Перпендикулярно им у окна расположись три стенда о творческом пути писателя. Стенды были выполнены кустарным способом и подписаны трафаретными надписями. Несмотря на это композиция стендов была достаточно информативной и уютной, хотя и устарелой. На них была представлена биография Галимзяна Ибрагимова, творческое наследие, родственники и соратники писателя. Стендовые экспозиции, вывешенные на стенах, были дополнены деревянными шкафчиками (также выполненные кустарным способом, но по стандарту экспозиционных витрин, когда смотровое стекло располагается под углом 45 градусов), в которых под стеклом размещались копии документов о писателе, копии бумаг, литературные и журнальные статьи, книги с произведениями и научно-критической литературой. Таким образом, комната музея в 12 кв.м. на первом этаже нашей гимназии вмещала интересный фактологический и литературный материал о Г.Ибрагимове. Надо отметить, что личных вещей писателя в музее нет. Поэтому он является литературным, а не мемориальным. Мемориальный музей Г.Ибрагимиова находится в деревне Султанмуратово в Башкортостане. Наш музей является единственным музеем Г.Ибрагимова как в Казани, так и в Республике Татарстан и в этом его уникальность!

После проведения капитального ремонта в стенах гимназии в музее появились новые книжные шкафчики для изданий разных лет и рукописных документов. В 2022 году, в рамках реализации гранта, передо мной возникла наболевшая цель создания макета электронной версии новой стендовой экспозиции музея Ибрагимова. Самой сложной задачей при создании новой экспозиции была систематизация и компоновка материалов, фотографий о Галимзяне Ибрагимове. Стоял вопрос о том, опираться ли на старую фабулу изложения биографии писателя или сделать ее кардинально новой. В итоге, было принято решение сохранить ключевые ветки фотографий, но сделать другую компоновку и добавить несколько новых фотографий. Кроме того, все стенды подписаны словами писателя о жизни, предназначении человека, школе, литературе, что также делает образ его личности более понятным и приближенным к ученикам и посетителям музея. Таким образом был реализован системный подход в репрезентации основных фактов о Галимзяне Ибрагимове. Всего было отсканировано и подписано более 150 фотографий, из которых 119 фотографий вошли в окончательный вариант экспозиции.

Новые стенды окрыли новую страницу в истории Литературного музея Г.Ибрагимова. Я рада, что эти стенды будут полезны продолжительный период времени для всех гостей музея, в первую очередь для учеников нашей гимназии. Но это не значит, что и их в свое время не придется реставрировать и делать актуальными для молодого поколения. В любом случае на сегодняшний день Литературный музей Галимзяна Ибрагимова продолжает свою новую интересную жизнь в стенах 17 гимназии города Казани.

**Милли тәрбия - заманыбызның актуаль проблемасы**

**Хайбуллина Зубарджат Габделхаковна**

*МБОУ "Усалинская СОШ" Мамадышского района РТ*

Мәктәбебездә милли тәрбия, гореф-гадәтләрнең сакланышы турында таныштырганчы, аның тарихы хакында бер-ике сүз әйтеп китми мөмкин булмас, чөнки киләсе елга авылыбызда беренче мәдрәсә эшли башлаганга 110 ел була. 1928 нче елга кадәр авылда ике мәдрәсә эшләп килә, шушы елны кирпечтән яңа мәктәп бинасы салына. 1950 нче елдан урта мәктәп буларак балаларны кабул итә. Биредә 22 авылдан җыелып укыйлар, балалар саны 640 ка, параллель класслар 6 га җитә.Уку-укытуның куелышы, укытучыларның әзерлеге ягыннан Усали мәктәбе Республика күләмендә танылa. 1964 нче елда "Совет мәктәбе" ("Мәгариф") журналының бер саны махсус Усали урта мәктәбенә багышлана.

Шундый бай тарихы булган мәктәбебездә халкыбызның борынгы гореф-гадәтләре, йолалары нигезендә укучыларны милли рухта тәрбияләү мөһим бурычларның берсе булып тора. Шулай ук бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты.

Күпмилләтле Татарстан мәктәпләрендә дәүләт һәм туган телләрне үстерү, милли үзаң һәм патриотизм тәрбияләү – бик мөһим эш юнәлешләренең берсе һәм бу юнәлеш Федераль дәүләт белем бирү стандартларында аерым ассызыклана. Милли мәгариф шәхеснең җитлегү-камилләшү процессының нигезе, җәмгыятьнең мәдәни һәм интеллектуаль үсеш дәрәҗәсе күрсәткече. Бүгенге көндә мәктәп әлеге сыйфатларны формалаштыруның үзәге, сүнмәс учагы булып тора.

Иң асыл рухи-әхлакый кыйммәтләр, дөрес яшәү кануннары ислам тәгълиматында һәм татар халкының тәрбия тәҗрибәсендә тупланган Халык бәйрәмнәре, аларга караган күп кенә гореф-гадәт, йолалар шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләрнә күнектерү чарасы да булып хезмәт итә. Бу чараларда халыкның олысы-кечесе теләп катнаша, һәр буын кешесе анда катнашу тәртибен гадәт итеп үзенә сеңдерә.

Тотрыклы (толерант) шәхес тәрбияләү – ул укучыларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз. Без балаларда үз халкыбызга, үз илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, кайда яшәүләренә һәм нинди милләт кешеләре булуга карамастан – барлык халыкларны, аларның мәдәниятен, гореф-гадәт, традицияләрен хөрмәт итәргә, табигатьне яратырга өйрәтәбез, гомумкешелек

кыйммәтләре белән таныштырабыз. Бу мәктәп күләмендә эшләнгән стендлар һәм мәктәп музеенда милли төбәк компонентларырда да чагылыш тапкан. Шулай ук күренекле якташларыбыз, танылган шәхесләребез белән дә очрашулар оештырылып тора.

Шуңа без, укытучылар, милли тәрбия биреп,халыкның гореф-гадәтләре, милли мирасы, җырлары, биюләре, уеннарын һ.б. бала күңеленә кече яшьтән кертеп калдырырга тырышабыз. Укучыларыбыз тәнәфесләрдә дә татар халык уеннарын яратып уйныйлар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: башкаларга карата түземле, тыңлый белгән, җәмгыятьтә үз сүзен әйтә алган толерант шәхесне милли гореф-гадәтләр, йолаларга таянып, гаилә белән мәктәп берлектә генә тәрбияли ала. Шуңа да укучыларда милли үзаң булдыру – безнең төп бурычыбыз.

Файдаланылган чыганаклар.

1.Мозаффарова М.Г. "Әдәбият" предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр. Казан. ТРМҮИ. 2014;

2.Садыйкова Д.Укыту-тәрбиядә милли-төбәк компоненты.// "Мәгариф"журналы,2003 №11, 54б.

**Развитие критического мышления учащихся 9-х классов на уроках литературы (по методу "Шесть шляп мышления")**

**Комарова Елена Юрьевна**

*учитель русского языка МБОУ "Школа №101 имени П.А. Полушкина - Центр образования"*

Задачей школы на современном этапе является обеспечение всестороннего развития мышления учащихся. Актуальность развития критического мышления подтверждается требованиями ФГОС к метапредметным результатам освоения основной образовательной программы, которые во многом соответствуют навыкам развитого критического мышления.

Наше исследование предполагает выбор и применение на практике эффективных методических инструментов развития критического мышления учащихся с точки зрения содержания и формы обучения. Большие возможности в развитии мыслительных навыков учащихся на уроках литературы предоставляет изучение литературно-критических статей. Данный вопрос был освещен в пособиях методистов XX века В.В. Голубкова, Л.А. Оголихина, В.Д. Войтушенко и др.), а также в научных работах последних лет (Н. Свирина, В.Н. Крылов, Н.Н. Зверев). Научная новизна нашего исследования заключается в обосновании некоторых приемов изучения литературно-критических произведений на современном уроке литературы, способствующих развитию критического мышления. Практическая значимость исследования заключается в разработке урока литературы на материале романа А.С. Пушкина «Евгений Онегин» и критических статей о романе, с использованием интерактивного метода обучения «Шесть шляп мышления».

Для развития критического мышления ученики должны анализировать, выявлять факты, изучать доводы, выявлять противоречия и т.п. Школьникам предлагается сопоставление литературно-критических оценок одного и того же произведения. Вариативность истолкований способствует созданию проблемной ситуации на уроке.Крайне важным представляется также задействовать интерактивные формы обучения. Эффективныминтерактивным методом является разработанный английским психологом Эдвардом де Боно метод «Шесть шляп мышления».Это способ решения проблемного вопроса посредством разделения процесса мышления на шесть типов.Метод помогает увидеть явление с разных позиций, в результате чего складывается наиболее полная картина.

В рамках данного исследования был разработан урок литературы«Образ Онегина и тип «лишнего человека» в русской литературе» по роману А.С. Пушкина «Евгений Онегин»с использованием метода «Шесть шляп мышления». Урок был апробирован в рамках образовательного процесса в МБОУ "Школа №101 имени П.А. Полушкина - Центр образования". На уроке происходит обращение к критическим работам о романе В.Г. Белинского и Д.И. Писарева. Для реализации метода учащиеся были разделены на шесть групп, каждая из которых выбрала цвет шляпы, указывающий на определенный тип мышления. Группам необходимо было на основании текста романа и текстов статей критиков подготовить сообщение об образе Онегина в соответствии с выбранным типом мышления (позитивный, негативный, эмоциональный и т.д.). Метод «Шесть шляп» способствовал рассмотрению характера пушкинского героя с различных сторон, что помогло учащимся при содействии учителя понять многогранность его образа и ответить на проблемный вопрос урока.

Анализ результатов исследования позволил сделать следующие выводы:

1) Для развития критического мышления учащихся на уроках литературы эффективно обращение к разным критическим оценкам программного художественного произведения. Сопоставление предложенных точек зрения углубляет анализ произведения, способствует формированию оценочно-критической позиции ученика.

2) Интерактивный метод «Шесть шляп» повышает активность учащихся на уроке; способствует развитию мышления осознанного, самостоятельного, рефлексивного, т.е. развитию мышления, которое и называют критическим.

**Список литературы**

1.Бочаров А. Г. Жанры литературно-художественной критики: Лекции. – М., 1982. - 51 с.

2.Войтушенко В. Д., Король Н. И. Изучение литературно-критических материалов в школе. – Киев.: Рад. Школа. 1982. -175 с.

3.Голубков В.В. Новый путь изучения художественных произведений и составления для литературных бесед и письменных работ. – М., 1914.-200 с.

4. Зверев Н.Н. Развитие самостоятельности суждений старшеклассников в процессе изучения литературно-критических статей: на материале IX класса: автореф. дис.... к-та пед. наук. - М., 1992. - 16с

5.Костылев О. Л. Критическая статья на уроке литературы. – Л., 1976.-192 с.

6.Крылов В. Н. Использование критических статей в современном школьном изучении литературы // Литература в школе.  – 2016. -№9. С. 20-23

7.Оголихин Л.А. Изучение литературно-критических статей в школе.  М., 1954.-184 с.

8.Примерная образовательная программа основного общего  образования // [Электронный ресурс] // Сайт Министерства образования и науки РФ. http://www.mon.gov.ru

9.Пушкин А.С. Сочинения. В 3-х т. Т. 2.  М.: Худож. лит., 1986. - 527 с.

10.Райхин Д.Я. Белинский в школе. – М.: Просвещение, 1964. – 160 с.

11.Свирина Н.Критические этюды на уроках – утверждение нелинейности литературных образов // Литература. – 2010.– №16. –  С. 38–41

12.Халперн Д. Психология критического мышления. — СПб., 2000. —(Сер.«Мастера психологии»).

13.Хрестоматия по литературной критике для школьников и абитуриентов /сост.  Л. А. Сугай. М.:  РИПОЛ-классик 1998. - 766 с.

14.Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования (утв. приказом МинОбрнауки РФ от «17» декабря 2010 г. № 1897// [Электронный ресурс] // www.standart.edu

# Туган телебезне укытуда заманча һәм инновацион технологияләр

**Г.Н. Айнуллова, Л.К. Шайхуллина**

*МАОУ “Лицей № 131”, г. Казань*

Хәзер компьютер технологияләре кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә нык үтеп керде. Бер генә белгечлекне дә, профессияләрне дә аңардан башка күз алдына китереп булмый.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш - үзгәрешне тәэмин итә. Моннан берничә еллар элек уку - укыту процессында укытучының төп эш коралы булып такта белән акбур торса, хәзер инде хәл бөтенләй башкача.

Татар теле дәресләрендә укучыларны кызыксындыру, дәресне мавыктыргыч итеп үткәргәндә компьютер куллану бик отышлы. Хәзерге көндә электрон белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора.

Компьютер технологияләре белем бирүнең эчтәлеген, методларын, оештыру формаларын сыйфатлы итеп үзгәртә, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен, танып белү сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Яңа педагогик технологияләрне куллануның төп максаты - белемле, тәрбияле, тормышта үз юлын табарга әзерлекле, яхшыны яманнан аера, тиешле карар кабул итә белгән шәхес тәрбияләү.

Нәрсә соң ул инновацион технологияләр? Innovation –инглиз сүзе “яңалык” дигән сүз. Технолгия-грек сүзе сәнгать,осталык дигәнне белдерә. ”Технология “һәм” методика” сүзләре мәгънә ягыннан якын: ”технология” төгәл билгеле нәтиҗәгә юнәлтелгән метод һәм ысуллар чылбырын тәшкил итә.

Инновацион технологияләр файдаланып белем бирүнең мөһим бурычлары түбәндәгеләр:

-укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уяту;

-аның танып белү активлыгын үстерү;

-укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;

-белемнәрен тирәнәйтү.

Без, татар теле укытучылары, дәресләрне нәтиҗәлерәк уздыру өчен яңа формалар һәм алымнар эзлибез, яңа технологияләрне яки аларның элементларын актив кулланабыз. Мәсәлән, укучыларның белемнәрен күтәрүдә аеруча эффектив булганнары: электрон дәреслекләр һәм кулланмалар; аларны компьютер һәм видеопроектор ярдәмендә эшләтеп, укучыларга зур күләмдә мәгълүмат бирергә мөмкин. СД-дискларга (аудиоязмалар) яздырылган электрон белешмәләр мультимедиа энциклопедияләр дә дәресләрне нәтиҗәле итүдә гаять зур роль уйный.

Компьютер, күрсәтмәлекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Хәзерге вакытта дәресләрдә мультимедиа чараларын еш кулланабыз. Мультимедиа технологияләрен куллану яңалыклар белән кызыксыну теләге уята. Мультимедия технологиясе слайд-иллюстрацияләр күрсәтергә, читтән торып экскурсия үткәрергә, бирелгән темага проект эшләргә һәм аны якларга мөмкинлек бирә. Татар әдәбияты дәресләрендә мультимедия проектлары төзү, традицион реферат язуны алыштыра.

Дәресләребез өчен презентацияләр ясау укучыларда зур кызыксыну уята. Аларны яңа теманы аңлатканда, материалны ныгытканда, язучыларыбызның тормыш юллары белән таныштырганда, класстан тыш чараларда еш кулланабыз.

Дәресләребездә интерактив такта белән дә еш кулланабыз. Аның белән эшләү бик уңайлы: слайдлар күчерергә, төрле төсләрне кулланып эшләргә мөмкин. Яңа тема, яңа күнекмәләр формалаштыруда интерактив такта укытучы өчен дә зур ярдәм, укучылар өчен дә кызыксындыру чарасы һәм тирәнрәк белем алу мөмкинлеге булып тора. Компьютер куллану дәресне кызыклырак, җанлырак итә.

Информацион технологияләрне куллану, баланың иҗади мөмкинлеген, укуга кызыксынуын һәм мөстәкыйльлеген үстерә, күзаллауларын киңәйтә, фикерләү сәләтен камилләштерә.

Интернет-ресурслардан дөрес файдалану бик күп дидактик мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итә: рус телле балалар татар телендә текстлар тыңлый, татарча уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерә, ишетеп аңлау (аудирование) биремнәре эшли. Билгеле булганча, Интернет челтәрендә мәгълүмат эзләү – фәнни-эзләнү методының бер формасы, шуңа да ул дәреслек кысаларыннан чыгып, яңа белем эзләүдә безгә бик ярдәм итә.

Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Төрле технологияләр, компьютер, мультмедиа технологияләре күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикри тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп Безнең укучыларыбыз бөтен яктан да үрнәк балалар булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Н. В. Агапова. Перспективы развития новых технологий обучения. – М.: ТК 1. Велби, 2005 – 247 с.

2.Балобанова А. Компьютер технологияләрен кулланып. // “Мәгариф” 4.журналы / 2004 ,№6

3.Вәлиев Р. Информационное обеспечение процессов образования.// 6.“Мәгариф” журналы/ 2005, № 6.

**Китапка мәхәббәтне ничек тәрбияләргә?**

**Хафизова Г.С.**

*МБОУ Школа №70*

*"Китап уку – гаҗәеп бер тәрәзә ул, шуның аша*
*балалар дөньяны һәм үзләрен-үзләре күрәләр*
*һәм танып беләләр"*
*В.А. Сухомлинский*

Китап укый торган кеше ул – фикерләүче кеше, социаль актив шәхес, җәмгыятьнең рухи үсешен тизләтергә, әхлак культурасын арттырырга сәләтле. Әмма бүгенге дөньяда – мәгълүмәт технологияләре үсеш алган заманда – баланы китапка җәлеп итү шактый катлаулыга әверелә бара. Ни кызганыч, бүген гаиләләрдә матур әдәбият, китап укыган ата-аналар да сирәк очрый. Китапны телевизор, компьютер, планшетлар кысырыклап баралар. Балаларның укымавы бүгенге көндә бик күп проблема тудыра. бүгенге көндә мәктәп укучылары укытучы таләп иткәнгә күрә генә укыйлар, ансы да мәктәп программасына кергән әсәрләр генә. Кыскасы, китап белән кызыксыну әкренләп кими бара. Бу без әдәбият укытучыларын гына түгел, күпләрне борчуга сала. Әле проблемадан ничек котылырга соң? Балага ничек ярдәм итәргә? Ничек итеп баланы китаплар дөньясына алып керергә? Аны балалар әдәбияты белән танышудан, китап укудан ләззәт, хозурлык табарга өйрәтергә? Укучыларда ничек итеп мөстәкыйль рәвештә китап уку теләге уятырга? Бу сораулар миңа һич тынгы бирми. Әдәби әсәрне өйрәнү дәресләренең эчтәлеген укылган әсәрне (өзекне) берничә тапкыр кабатлап сөйләү, укучыдан үзенә ошаган урыннарны кат-кат укыту кебек эш төрләреннән мөмкин кадәр арынырырга кирәктер, минемчә. Әдәбият дәресләрен бүгенге көн таләпләренә туры китереп, кызыклы итеп, балалар кызыксынырлык итеп ничек укытырга соң?

Беренче сыйныфта "Әдәби уку" дәресләре башлангач, баланы мәктәп китапханәсенә алып барырга киңәш итәм. Әле дөньяга күзе ачылып килә торган вакытта кызыксыну туа. Алар беренче тапкыр "китап йортына" керәләр. Карыйлар, сораулар бирәләр, күзләре яна башлый, китапханә кагыйдәләре, тәртибе белән танышалар. Менә шуннан башлана инде ул кызыксыну. Укучының бер кечкенә генә китапны өенә алып кайтып, әти-әнисенә күрсәтүе, укып чыгуы файдалы нәтиҗә бирә. Дәрестән тыш эшчәнлек вакытында ешрак кереп, китапханәдәге апа табып биргән китаплардагы шигырьләрне уку галәмәт тә кызыклы булуы ачыклана, бала татар әдәбияты белән мөстәкыйль кызыксына башлый.

Башлангыч сыйныфта укучыларга дәфтәр башлатып, укыган китабының исемен, авторын, геройларын язып куярга, ике-өч җөмлә белән эчтәлеген дә язып бару да уңай нәтиҗә бирә. Бала тезисларны аерып алырга, төп мәгънәне язып куярга өйрәнә, геройларның исемнәрен истә калдыра, аларның характер үзенчәлекләрен билгеләп куя.

Дәресләрдә әдәби әсәрне өйрәнгәндә, мавыктыргыч итеп, интонация белән, рольгә кереп, кычкырып үзем укый башлыйм. Бала игътибарын юнәлтә, кызыксыну туа. Аннан үзләренә укытам. Озынрак хикәя булганда, иң кызык урында, "Хәзер нәрсә була инде?" дигән урында туктап калам. Аннары нәрсә булганын, үзегез укып белерсез, дим. Балалар: "Укыгыз инде, беләсе килә бит",- ди башлыйлар. Чыннан да, балалар өйгә бирелгән әсәрне укып киләләр. Күп укыган бала иншалар, диктантларны җиңел яза, хаталарны ңа азрак ясый. Китапны яратып укыган бала текстның эчтәлеген аңлый, геройлары белән яши, алар өчен борчыла, елый, көлә, бер сүз белән әйткәндә, чын йөрәктән укый.

Үзлегеннән китап укый башлагач, аңа әсәрнең эчтәлеген сөйләтү, кирәк. Блум ромашкасы ысулын куллануны кулай күрәм.

Бала кычкырып укый, ә үзе текст нәрсә турында икәнен уйламый. Бу проблемадан котылу өчен, урта сыйныфларда инсерт ысулын куллану файдалы нәтиҗә бирә. . Бу ысулны куллануның уңышлы ягы шунда, укучы текстны пассив укымый, ә белергә, аңларга теләп, игътибар белән кат-кат укый. Укучыларны тамга кую билгеләре белән таныштырып чыгарга кирәк, чөнки текстның кырыена тамгалар куеп барырга туры киләчәк.

˅ *(галочка)* тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

**+** *(плюс)* тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

– *(минус)* тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

**?** *(сорау)* тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

Өлкән сыйныфлада балаларга буктрейлерлар ясарга тәкъдим итәм.. Башта кәгазь вариантта, аннары презентация рәвешендә, зуррак классларда видеоролик рәвешендә ясарга өйрәнәбез. Китапнамә ясау өчен, китапның эчтәлеген белергә кирәк. Шулай итеп, балалар китапны укып чыгарга тиеш булалар.

Шушы урында “Кешегә балык бир, ул бер көн тук була, син аны балык тотарга өйрәт- ул көн дә тук була” дигән мәкальне китерәсем килә. Без балаларны “балык тотарга өйрәтергнә тиешбез.

Сүземне Роберт Миңнуллин сүзләре беләнтәмамлыйсым килә: “Иман нурын да, дөнья цивилизациясенең казанышларын да, халкыбызның бай тарихын да, рух ныклыгын да безгә китап биргән. Шуңа күрә дә без Китапка чиксез рәхмәтле. Бүгенге көндә безнең төп рухи таянычыбыз китап булырга тиеш. Китапсыз күңел-буш күңел, китапсыз йорт-нурсыз йорт, китапсыз милләт-киләчәксез милләт. Бәхетебезгә, без андыйлар түгел!Әлегә...”

Китап уку бүгенге көн балалары өчен матур гадәткә әйләнсен иде.

**Гыйбрәтле язмышлар. Зәйнәп Хәсәни (1887-1968)**

**Хуҗина Рузилә Тәлгать кызы**

*Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г. Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе туган тел укытучысы*

Телгә, тарихка, мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләүдә мәктәп музейларының роле әйтеп бетергесез зур роль уйный. Гимназиябез татар халкының мәгърифәтче кызы Ф.Г. Аитова исемен йөртә. Гимназиядә дүрт музей эшли. Шуларның берсе – Фатиха Аитова музее. Стендларда Фатиха апа белән бер чорда яшәгән, аның белән бергә мәгърифәт нурлары тараткан игелекле ханымнарның портретлары да бар. Шуларның берсеннән безгә мөлаем йөзле, зыялы чибәр ханым карап тора. Бу –XX гасыр башы татар яңарышы тарихында билгеле урын алып торган Әхмәтгәрәй Хәсәни хатыны Зәйнәп ханым. Гаять киңкырлы эшчәнлек алып барган, иренең якын киңәшчесе, хезмәттәше һәм шул ук вакытта Ф.Аитованың уң кулы булган ханым турында нәрсәләр беләбез?

Эшнең максаты – Зәйнәп апа Хәсәни турында материаллар табу, аларны музей эшчәнлегендә куллану.

Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар билгеләнде: Зәйнәп апа турындагы истәлекләр белән танышу, аның якташлары истәлекләрен өйрәнү, башка музейлар белән элемтәгә керү.

Алда куелган максат һәм бурычларны тормышка ашыру өчен,Тәэминә апа Биктимерованың, Мөхәммәт ага Мәһдиевнең хезмәтләре өйрәнелде. Зәйнәп апаның әтисенең төп чыгышы булган Әтнә районы Түбән Көек авылы кешеләренә мөрәҗәгать ителде. Тукай музееныңөлкән фәнни хезмәткәре Лена Тябина фикерен дә тыңладык.

XX гасыр башында татар халкының мәдәнияте, әдәбияты нык алга китә. Гаярь ир-егетләребез белән беррәттән халкыбызга аң-белем бирү юлында хатын-кызлар да күтәрелә. Кызларыбызга дини белем бирү белән бергә дөньяви белемнәрнең кирәклеген дә аңлаган ханымнар үз акчаларына мәктәп-гимназияләр ачарга хыялланалар. Хыялланып кына калмыйлар, барлык көчләрен туплап, шул юнәлештә эшне башлап та җибәрәләр. Татар халкының үсешенә тормышын бөтен тулылыгы белән багышлаган Фатиха ханым ялгыз булмый. Ул үз тирәсенә белемле, актив ханымнарны туплый.

Зәйнәп - Ногман хаҗи кызы, ә Ногман абзый үзе тумышы белән Әтнә районы Түбән Көек авылыннан. Ул 12 яшендә авылыннан чыгып китә, казакъ җәйләүләрендә көтү көтеп, Оренбург, Казан байларына хезмәт итеп байлыкка ирешә, үз акчасына 13 мәчет, 7 мәдрәсә салдыра. Кызы Зәйнәп тугач, ул гувернантка яллый. Зәйнәп татар теле белән беррәттән рус, француз телендә сөйләшкәннәрне ишетеп үсә. Өйләрендәге китапханәдә татарча, төрекчә китаплар белән бергә рус һәм Европа халыкларының класссик әдәбияты үрнәкләрен күрергә мөмкин була. Үскәч, сәүдәгәр Сибгатулла хаҗи улы Әхмәтгәрәйгә кияүгә чыга. Ире “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә укыган белемле кеше була, этисе, укытучы яллап, өйдә дә укыта. Шуңа күрә ире дә төрек, гарәп, француз, рус телләрен яхшы белә. Әтисе аның сәүдәгәр булуын теләсә дә, егет әдәбиятка тартыла: үзен язучылык, тәрҗемә өлкәсендә сынап карый. “Гасыр” исемле нәшрият ачып, рус классик әдәбиятын татар телендә бастырып чыгаруга күп көч куя. 1910 нчы елда тәҗрибә туплау максатыннан Швейцария, Франия, Германия, Польшада булып кайта.

Менә шулай затлы тәрбия алган яшьләр матур гына үз тормышларын башлап җибәрәләр. Әдәбиятны яхшы белгән Зәйнәп иренә нәшрият эшләрендә ярдәм итә. Алар янына татарның күренекле, алдынгы яшьләре тартыла. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин, Г.Коләхмәтов тәкъдиме белән ул “Аң” журналы чыгара башлый. Ә бу журналның җаваплы секретаре Зәйнәп Хәсәни була.

Зәйнәп ханым җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Фатиха апа Аитова ачкан кызлар мәктәбендә (1909) һәм соңрак ачылган гимназиясендә (1916) ул попечительләр советы әгъзасы була. Фатиха Аитованың мөселман кызлары өчен мәктәп ачарга йөрүе зур каршылыклар аша гына тормышка аша. Менә шул каршылыкларны үтәргә белемле, акыллы, тәрбияле ханым Зәйнәп Хәсәни зур булышлык күрсәтә. Бу ике ханымның татарлар өчен куйган хезмәтләре бәяләп бетергесез. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, мөселман яралылары өчен махсус лазарет ачуны башлап йөрүчеләр

дә алар икесе була. Лазарет өчен кирәкле әйберләрне дә Хәсәниләр йортында тегәләр. Ярдәм итү өчен киң җәмәгатьчелектә хәйрия эшләре башлап җибәрәләр. Зәйнәп апа Фатиха апа белән гомер буе дус була. Фатиха апа авырып, 16 ай буе түшәктә ятканда, аның янына соңгы көннәренә кадәр килеп йөри.

1917 елда Бөтенрәсәй мөселман хатын-кызлары корылтаен оештыруда башлап йөргән Хәдичә Ямашева-Таначевага(Хөсәен Ямашевның сеңлесе) иң зур ярдәмне күрсәтүчеләрнең берсе дә ул. Корылтайда төшкән фотода Зәйнәп апа Фатиха Аитова белән янәшә утырган (фото стендта бар).

Советлар илендә халык азатлыгы өчен көрәшкәннәрне "халык дошманнары" дип атау, аларны сөргеннәргә сөрү, дошман эзләү процессы башлана. Красноярск краена сөргенгә җибәрелгән Хәдичә Ямашева шунда үлгәч, Хәдичә апаның ире Вәлидхан абый Зәйнәп апага мөрәҗәгать иткән. "Зәйнәп, — дип яза ул, — Син безнең дустыбыз. Мондый зур үтенеч белән бары зур дусларга гына мөрәҗәгать итәргә була". Хәдичәнең каберенә утыртырга гарәп язулы таш сорый ул, һәм Зәйнәп ханым җибәрә.

Октябрь революциясеннән соң татар халкына хезмәт куйган игелекле гаиләнең тормышы җимерелә. Ире Әхмәтгәрәйне 1931 нче елда кулга алалар (сәбәбе – эмиграциядәге язучы Гаяз Исхакый белән хат алышкан, аның әсәрләрен бастырган). 1933 елда Әхмәтгәрәйнең "Мине сөргенгә җибәрәләр, килә алырсыңмы?" дигән хатына Зәйнәп ханымның җавабы -"Дөньяның кайсы почмагында сиңа урын бирсәләр, мин шунда синең яныңа барам". Без декабристларның курку белмәс хатыннары турында сокланып сөйлибез, алар белән горурланабыз, ә үзебезнең каһарманнарыбыз турында бик аз беләбез. Ләкин Зәйнәп апага Себергә барырга туры килми. Ире Әхмәтгәрәйне атып үтерәләр.

Ә хәзер хөрмәтле язучыбыз М.Мәһдиев истәлекләренә күз салыйк. "Халык дошманы"ның хәлен белергә кем килә? Беркем дә! Хәтта аның туган-тумачалары да күрмәмешкә салышалар. Минем үз башымнан узган хәл бу: әтине "алгач", аның иң якын туганнары да бездән ераклаштылар... Гали Рәхим янына исә("Борынгы татар әдәбияты тарихы" исемле гыйльми хезмәтләр авторы, күренекле фольклорчы, текстолог, драматург, шагыйрь, прозаик һәм, ниһаять, мәшһүр "Кәк-күк"нең авторы!) бердәнбер Зәйнәп апа Хәсәни (... әле 1968 елда гына дөньядан китте, мин аның янында ике тапкыр булып, бик күп истәлек язып калган идем) килеп китә. Ул Гали Рәхимгә ризыклар, иреннән калган (ире Әхмәтгәрәй 1934 елда ук Сталин корбаны булган) кием-салым алып килгәли."

(Мөхәммәт Мәһдиев" Каһәрләнгән язмыш" мәкаләсеннән)

Мөхәммәт абый Мәһдиевнең томнарында Зәйнәп апа турында язма табылмады, үзе исәнендә аны бастырып чыгара алмаган ахрысы, дип уйлыйбыз. Ләкин аның язмышы бөек язучыбызны кызыксындырган, чөнки әтисе шулай ук "халык дошманы" тамгасын алган кеше була, Мөхәммәт абый архивлардан әтисенең төрмә документларын таба, өйрәнә, утырып елый.

Шушы истәлек үзе генә дә белемле, затлы гаиләдә үскән, кешелекле Зәйнәп Хәсәнигә зур бәя булып тора.

Туган телен камил белгән, шунлыктан башка телләрне дә үзләштерә алган Зәйнәп апаның туган йорты Нәриман һәм Фатих Кәрим урамы чатында урнашкан, әле дә бар.

Тукай һәм Зәйнәп Хәсәни

Замандашлары язуы буенча Г.Тукай хатын-кызлар белән әңгәмә корудан кача, ятсына торган була. Тик аның бер хатын-кыз белән кыенсынмыйча, үз иптәше кебек сөйләшүе билгеле. Хәсәниләр белән беренче күрешү турында олуг әдибебез Ф. Әмирхан язып калдыра. 1912 елда Хәсәниләр дачасына кунакка чакырылгач, Тукай Фатихка:"Юк, хатын-кыз булган җирдә минем өчен уңайлык булмый инде. Син үзең генә бар, анда мин бармам", - дип баш тартмакчы була. "Ләкин шунысы гаҗәп, - дип яза Ф.Әмирхан, - барып җитеп, әвәлге чәй янында ук хуҗа хатын белән танышу мәҗбүрияте куелгач, ул моннан артык уңайсызланган шикелле күренмәде... Соңа таба инде ияләште вә сөйләшеп утыра башлады".

Алда без Зәйнәп апаның ире Әхмәтгәрәйнең "Аң" журналы чыгаруын әйтеп үткән идек. Г.Тукай журнал өчен махсус шигырь яза, һәм ул шигырь 1912 нче елның 15 декабрендә беренче санның тышлык битендә басылып чыга.

Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге ним белән...

Г.Тукайның соңгы көннәре дә Хәсәниләр белән бәйле. Безнең көннәргә кадәр сакланган ике хаты да Хәсәниләргә. Аның берсе Зәйнәпкә аталган. 1913 ел, 28 март." 8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурасын үземә күрсәтсәгез икән", - ди.

Тукай белән аралашырлык зәвыклы, әдәбият дөньясында, сәясәттә мәгълүматлы игелекле ханым Зәйнәп Хәсәнинең фотографиясе Тукай музеенда да бар. Килгән кунакларны Зәйнәп апа Хәсәни белән Тукай музееның өлкән фәнни хезмәткәре Лена Тябина таныштыра. Ул Зәйнәп Хәсәнинең Тукай белән танышлыгы хакында әйтеп уза, Хөсәен Ямашевның сеңлесе белән Зәйнәп апаның дуслыгын искәртә, игелекле хезмәтләрен атап китә.

Зәйнәп апа эзләреннән

"Без -тарихта эзлебез", - дип сөекле шагыйребез дөрес әйткән. Зәйнәп апаның тормышы минем үзем өчен бик кызыклы, гыйбрәтле, якын, чөнки мин Зәйнәп Хәсәнинең әтисе яшәгән Әтнә районы Түбән Көек авылында тудым, яшәдем.Кечкенә чагымда бабам белән кибеткә төшә идек. Кибет авылның нәкъ уртасында. Менә шунда бабам Галимҗан кибет, мәчет янәшәсендәге бер өйгә күрсәтеп, бу урында авыл бае Ногман өе булганын әйтә иде. Ул авылдан 12 яшьләрдә чыгып китсә дә, мал туплагач, Казанда үз тормышын корса да, авылда калган әти-әнисенә, авылдашларына ярдәм иткән булып чыга.

Зәйнәп апа турында үз сүзен әйтә алган икенче әңгәмәдәшебез инде олы яшьтә булса да, хәтере ачык Зәйтүнә апа Юсупова. Ул озак еллар Түбән Көек авылында башлангыч сыйныфлар укыткан, хәзерге көндә кызы-кияве белән Мамадыш районында яши. Зәйтүнә апа Зәйнәп Хәсәнине үз күзләре белән күргән кеше. Аның каенанасы Латыйфа апага Зәйнәп апа, әтисенең туган авылына кунакка кайткач, күчтәнәчләр, бүләкләр кертә. Латыйфа апа бүләк материалдан теккән күлмәген бик яратып ашларга кия торган була. Зәйтүнә апа Зәйнәп апаны кеше белән итагатьле сөйләшүчән, тәрбияле әңгәмәдәш буларак искә ала, аның авылга еш кайтып йөргәнен әйтә.

Зәйнәп апаны якыннан күргән өченче әңгәмәдәш Флюра апа Фазылҗанова. Ул да Түбән Көек авылыннан, хәзерге вакытта Казанда яши. Флюра апаның әнисе Рауза белән Ногман абый туганнар булып чыга. Рауза апалар Ногман байдан калган йортта яшәгәннәр. Ногман байның өе калай түбәле була, ә авыл кешеләренең ул вакытта әле түбәләре тактадан. Җил, яңгыр вакытында калай түбәнең тавышы өйгә ишетелә иде, ди. Шул вакытта әнием:" Кайчан без дә кеше шикелле такта түбәле йортта яшәрбез икән", - дип әйтә иде ди. Андый өй авылда берәү генә, биек баскычлы(подвалы да була инде), бүлмәләр арасында зур пыялалы ишекләр. Өйне сүтеп, шул нигезгә яңа йорт салалар. Шул вакытта белмичә нинди кыйммәтле агач җиһазны утка яктык, дип сөйли Флюра апа. 8 нче классны укып бетергәч, ул Казанга килә. Зәйнәп апа Хәсәни ул вакытта инде квартирасында берүзе генә яши, һәм ул Флюра апаны үзе янына өйдәш итеп чакыра. "Миндә торып укырсың", - ди. Ләкин Флюра апаның Казанда торасы килми, ул туган авылына кайтып китә. Эшкә керә. Флюра апа Зәйнәп апаның чиста, урта хәлле кешеләр яши торган квартирада торганын әйтә.

Татар халкының энҗесе, өлгесе булган ханымнарыбызны онытырга хакыбыз юк. "Үткәнен белгәннең киләчәге дә өметле",- ди халык. Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Зәйнәп Хәсәнинең исеме яшәргә лаек, ул онытылырга тиеш түгел. Минхезмәтем белән аның якты хатирәләрен барлый алганмын икән, укучыларыбызга ирештерә алам икән, максатыбызга ирешәбез дип уйлыйм.

Зәйнәп апа турында материал туплаганда, Тәэминә апа Биктимерова хезмәтенә таяндык. Шуны да әйтеп үтәсе килә: музейда укучылар Фатиха апаны һәм анда укыган кызларыбызны җанландырып күрсәтәләр, вакыйгаларны үзләреннән сөйлиләр. Моның өчен директорыбыз Нәгыймова Зөммәрәт Шамиловна шул заман укытучылары һәм укучылары кигән күлмәкләр тектерде, калфаклар чиктерде.

Музеебызда татар халкының тарихи сәхифәләренә мөрәҗәгать итүне, татар дөньясында эз калдырган алдынгы карашлы ханымнарыбыз белән танышуны алга таба да дәвам итәрбез дип уйлыйбыз. Хәзерге буын татар тарихындагы күренекле шәхесләрне бик күп белә дип өздереп әйтеп булмый. Алар турында социаль челтәрләр аша, хәзерге заман таләпләренә туры китереп эшләнелгән, видеомәгълүмат таратырга кирәк дип уйлыйбыз."Без 41 нче ел балалары" кебек кинофильмнар төшерелсә дә исемнәрен мәңгеләштерүгә ярдәм итәр иде. Тукай,Фатих Әмирханнар белән аралашкан, Зәйнәп ханым да, башка күренекле тарихи шәхесләребез дә моңа бик лаек.

**Файдаланылган әдәбият**

1.Биктимирова Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. - Казан:"Алма-Лит", 2006. – 239 б.

2.Мөхәммәт Мәһдиев "Каһәрләнгән язмыш" http://beznenmiras.ru/mohammat-mahgiev-kaharlangan-yazmysh/

3. Милләт кызы//ҖАНЫ ҖӘННӘТТӘ БУЛСЫН!//14 сентябрь, №37 Тулырак: https://tatar-inform.tatar/news/archive/20-09-2006

**Эффективные техники формирования речевой культуры школьников или коммуникативных компетенций**

**Курбангалина Алина Тахировна**

*учитель русского языка и литературы МБОУ «Татарская гимназии №17 имени Г.Ибрагимова» Московского района города Казани*

**Речевая культура человека** – это соблюдение норм литературного русского языка. Так же это одна из составных частей общей культуры. Культура речи современного молодого человека неразрывно связана с культурой мышления, чувств, культурой поведения, определяет качества нравственного облика личности, влияет на эффективность его общения. **Коммуникативная компетенция** - это способность эффективно и качественно общаться.

На уроках русского языка и литературы основной целью является формирование речевой культуры и коммуникативных компетенций. Это кропотливая работа, требующая терпения, определенных навыков, смекалки, и педагогической подготовки.

Для достижения этой цели на уроках ежедневно проводится работа над обогащением словарного запаса учеников, над подвижностью того запаса слов, которыми они владеют, над составлением ясного и грамматически правильного целостного высказывания – текста.

Для обогащения словарного запаса эффективны следующие техники:

1. **Техника составления словарей**, где ученикам предлагается найти и выписать из текста незнакомые слова, найти и записать их значение, далее составить с данными словами словосочетания и предложения. Или почувствовать себя лексикографами и составить разного рода словари: «Словарь устарелых слов», «Толковый словарь», «Словарь компьютерных терминов», «Словарь диалектных слов» и т.д. Эта техника позволяет обогатить словарный запас ребенка. .
2. Составление **Кластера** для определенного слова. Ребенку предлагается подобрать к данному слову антонимы, синонимы, омонимы, фразеологизмы, в составе которых есть данное слово, обозначить морфологические признаки и, таким образом, систематизировать и закрепить информацию о данном слове.

Далее для этапа закрепления нового словарного запаса и активизации уже имеющегося эффективны следующие техники:

1. **Упражнений для расширения и закрепления словарного запаса**, которые можно выполнять как устно, так и письменно: 1) Составить небольшой рассказ, используя только существительные. «День. Труд. Конец. Выход. Дверь. Ключ. Подъезд. Машина. Ключ. Зажигание.» и тд. Или же рассказать маленькую историю с применением одних только прилагательных. Далее наступает очередь других частей речи. 2) Упражнение Алфавит. Учащиеся придумывают связанные слова, которые последовательно начинаются с букв алфавита по порядку. «Алена беседует вечером, гуляя до ели заветной, жестикулируя и красноречиво лелея милые нежные одуванчики. Паша рядом следует, тащит удобный фонарь хромированный, часто цепляя шустрое щебетание эмоциональным юмористическим языком». 3) Монофон. Ученикам предлагается придумать свою речь, слова которой начинаются на одну и ту же букву. Каждое из них связывают между собой, даже если смысл при этом страдает.
2. **«Снежный ком» -** один из участников произносит нераспространенное предложение, каждый следующий должен прибавить предложению один любой член предложения, повторив его целиком.
3. **«Диктант значений» -** учитель диктует не слово, а его лексическое значение. Ученики должны по значение определить слова и записать их. Например, учитель диктует: «Совокупность всех притоков реки, озера», ученики пишут «Бассейн» и тд.
